АЛДА – ЖИТДИ ЭШ

«Бердәм Россия» партиясенең Татарстандагы бүлеге утырышы узды

> 2

ПАРЛАМЕНТ УТЫРЫШЫННАН

Дәүләт Советында Татарстан бюджетын тикшерделәр

> 3-4

САНАЛУ ЧОРЫ

Җанисәп – үз фикереңне белдерү өчен яхшы мөмкинлек

> 6

ТАТАР КУБИНКАСЫ

София Перес үзендә әллә ничә милләтнең традицияләрен йөртә

> 6

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 157 (28739) | Чәршәмбе | 27 октябрь | 2021 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan @vatanymtatarstan /vatanimtatarstan

КОЯШ СҮНДЕ...

ЧАЛЛЫДАГЫ ШАРТЛАУДА ГОМЕРЕ ӨЗЕЛГӘН АДЕЛИНА ЗАГРИЕВАНЫ ХЕЗМӘТТӘШЛӘРЕ «КОЯШ» ДИП ЙӨРТКӘН

nabchelny.ru

Бу дүшәмбе Чаллы шәһәренең 48/20 йортында яшәүчеләрнең тормышын ике өлешкә бүлде. Унбиш подъездлы күпфатирлы торак йортның бер подъездында кичке сәгать бишләр тирәсендә көчле шартлау булды. Дүртенче һәм бишенче каттагы дүрт фатир бер мизгел эчендә хәрабәгә әверелде. Шактый озак азаплана торгач, коткаручылар җимерекләр астында калган дүрт кешене чыгарды. Аларның берсе – 22 яшьлек Аделина Загриева хастаханәдә вафат булды, тагын өчесе авыр хәлдә реанимациядә ята.

«Ахыргача исәндер дип көттек»

Шаһитларның сүзләренә караганда, җимерекләр арасыннан Аделинаны бик озак чыгара алмаганнар. Шул мизгелдә вакыйга урынында булган хезмәттәшебез, «Реальное время» басмасы журналисты Сергей Афанасьев әйтүенчә, кызны хәрабәләр арасыннан чыгару өчен коткаручыларга якындагы агачны кисәргә туры килгән. «Ул плитә астында 30 минутлап «мин монда» дип кычкырып ятты. Коткаручылар берөзлексез яндагы агачны кисте. Кич белән кисәк кенә минус 1–2 градуска кадәр суытты бит. Янда торган бер ир: «Ул монда өшеп тә үләргә мөмкин бит», – дип куйды. Әллә сүзләре рас килде, соңгы ярты сәгатьтә инде кызның тавышы ишетелмәде», – дип искә алды ул әлеге җан өшеткеч мизгелләрне.

Җимерекләр арасыннан чыгаргач кызны тиз арада хастаханәгә озаталар. Ул клиник үлем кичерә. Әмма, табиблар ничек кенә тырышса да, яшь кызның гомерен саклап кала алмыйлар. Якыннары, танышлары Аделинаны яхшы яктан гына искә ала. «Без аның белән бер мәктәптә укыдык. Бик яхшы кыз иде», – ди аның турында танышы Динара Солтанова. «ВТ» хәбәрчесе «КАМАЗ» оешмасында Аделина белән бергә эшләгән Фәнзилә Җиһаншина белән дә элемтәгә керде. Мәрхүмә хезмәттәшенең исемен ишетүгә: «Якты кояшыбызны югалттык», – дип авыр сулады Фәнзилә ханым. Аделина бу оешмага өч ел элек эшкә килгән. Моңа кадәр запас частьлар тезүче булып эшләгән 22 яшьлек кызны әле сентябрь аенда гына контролер итеп билгеләгәннәр. Яңа вазыйфада нибары өч атна гына эшләп калган ул. Ник дигәндә, авырып, «больничный»га киткән. Фаҗига булган көнне дә табибка барган, «больничные»н 28 октябрьгә кадәр озайтканнар.

– «Ватсап»тагы үзебезнең контролерлар төркемендә фәлән йортта шартлау булган дигән хәбәр таралды. Аделинаның шул йортта яшәгәнен беләбез. Исән булса гына ярар иде, дип аңа берөзлексез шалтырата башладык. Әмма трубканы алучы булмады. Соңгы минутка кадәр кояшыбыз исәндер дип өметләндек, – ди Фәнзилә апа.

Хезмәттәшләре Аделинаны эшне җиренә җиткереп башкара торган тырыш, бик пөхтә кыз иде дип искә ала. Олыны олы, кечене кече итә белгән. «Бүлмәгә кояш кебек елмаеп, ялт итеп килеп керә дә: «Пятерочка» выручает», – дип сузып, без – олы апаларына кәнфит ише тәм-том өләшә иде», – ди Фәнзилә апа күз яшьләрен яшермичә. Быел Аделина читтән торып югары уку йортына укырга кергән. Укуын тәмамлагач, дознаватель булып эшләргә хыялланган ул. Аделина хезмәт куйган «КАМАЗ» оешмасы җитәкчелеге мәрхүмәнең якыннарына матди ярдәм күрсәтәчәген әйткән.

Шартлау булган йортта яшәгән Ивановларның ике улы да фаҗигадә зыян күргән. Әниләре Рамилә Иванова сүзләренчә, шартлау вакытында алар дүртесе дә өйдә – 11 яшьлек төпчек уллары әти-әнисе белән башка бүлмәдә, олы уллары Женя йокы бүлмәсендә булган. Шартлау вакытында нәкъ менә йокы бүлмәсе җимерелгән. «Анда бар нәрсә ишелгән иде, үтеп керерлек түгел. Женя, Женя дип кычкырдык. Баштарак ул җавап бирмәде. Аннары үзенең тәрәзә янында икәнлеген әйтте. Аның ярты гәүдәсе тәрәзәдән чыгып торган булган. Улыбызны автобаскыч буйлап төшерделәр», – дип сөйләде Рамилә ханым. Хәзерге вакытта Женя авыр тән җәрәхәтләре белән реанимациядә ята. Табиблар аның хәлен авыр дип бәяли. Егетне Казанга күчерергә җыеналар. Ивановларның икенче уллары Артем да хастаханәдә. Әлегә ул шок хәлендә. Шартлаудан соңгы икенче көнне табибларга тагын бер кеше ярдәм сорап мөрәҗәгать иткән. Аны амбулатор рәвештә дәваланырга җибәргәннәр. Фаҗига корбаннарының тагын берсе – 70 яшьлек Владимир Рочев шулай ук авыр хәлдә реанимациядә. Аны вертолетта Республика клиник хастаханәсенә китерәчәкләр.

Ахыры 2 нче биттә >

Мәскәү безнең фикерне исәпкә алачак

Мәскәү безнең фикерне исәпкә алачак

Кремльдә республика парламентының Татарстан Президенты вазыйфасын юкка чыгаруга каршы фикере исәпкә алыначак. Әмма бу – күп кенә башка фикерләрнең берсе, дип билгеләп үткән Россия Президенты матбугат сәркатибе Дмитрий Песков.

«Закон проектына карата фикер бу. Закон проекты буенча эш кысасында Россиянең һәр субъекты фикеренә ихтирам хисе белән карыйбыз. Әмма бу – фикерләрнең берсе генә, һәм ул, һичшиксез, әлеге закон проекты буенча эшне дәвам иткәндә исәпкә алыначак, – дип белдергән Кремль вәкиле РИА «Новости» хәбәрчесенә. – Биредә ниндидер нигезләмәне законлаштыру турында сүз бармый. Нәкъ менә әйтелгән фикер генә бу. Эш барышында башка фикерләрнең дә ишетелүе әйбәт. Алар барысы да исәпкә алыначак».

Исегезгә төшерәбез: Татарстан Дәүләт Советы соңгы республика Президенты вазыйфасын юкка чыгару турында федераль закон проектын хупламады.

МРОТ күләме арта

Илдә хезмәткә түләүнең минималь күләме (МРОТ) 2022 елда аена 13617 сумга җитәчәк. Депутатлар кичә бу җәһәттән тиешле закон проектын беренче укылышта кабул итте.

Хәзерге вакытта МРОТ күләме 12792 сум тәшкил итә. Шул рәвешле ул 6,4 процентка, ягъни 825 сумга арта. Закон проектына аңлатма язуында билгеләп үтелгәнчә, проектны кабул итү 2,7 миллионга якын хезмәткәрнең эш хакын үстерү мөмкинлеге бирәчәк. Документта хезмәткә түләүнең минималь күләменең 2020 елдагы уртача хезмәт хакының 42 проценты күләмендә билгеләнүе күрсәтелгән.

Киләсе елда эшсезлек буенча пособиенең максималь күләме дә арта. Ул 12792 сум булачак.

Урманнар яңарды

«Экология» илкүләм проектының «Татарстанда урманнарны саклау» төбәк проекты кысасында республикада урманнарны яңарту эшләре төгәлләнгән. Барлыгы 3855 гектар мәйданда эшләр башкарылган. «Яңартылган урман мәйданы киселгән, корыган агачлар мәйданыннан ким булмаска тиеш. Бу – безнең эшне бәяләүдә кулланыла торган төп индикаторларның берсе. 2019 елда 2496 гектар мәйданда – өлгергән, артык өлгергән, зарарланган агачлар, 167 гектар мәйданда корыган агачлар киселгән иде. 2021 елда барлыгы 3855 гектар мәйданда агач утыртылды. Шулай итеп, максатчан индикатор 144 процентка үтәлде, – диде урман хуҗалыгы министры Равил Кузюров бу уңайдан. – Ягъни без киселгән агачларның бөтен мәйданында агачлар утыртып, 2024 елга билгеләнгән максатка ирештек».

Тагын шунысы бар: «Урманнарны торгызу өчен агач орлыклары запасы, кг» һәм «Утыртылган агачлар саны, мең данә» «Татарстан Республикасында урманнарны саклау» төбәк проектының өстәмә күрсәткечләре булып тора. Быелгы планда 11455 кг орлык әзерләү һәм 30863 мең данә үсенте утырту каралган.

Ил күләмендә мәҗбүри

Илнең барлык төбәкләрендә аерым категорияләр өчен COVID-19 инфекциясеннән мәҗбүри вакцинация кертелгән. Бу хакта Роспотребнадзор башлыгы Анна Попова коронавируска каршы көрәш буенча Хөкүмәт советы утырышында белдергән. Аның әйтүенчә, Россиянең барлык субъектларында баш дәүләт санитар табиблары мәҗбүри вакцинация турында карарлар кабул иткән. Моннан тыш ул халкының 60 проценттан артыграгы прививка ясаткан төбәкләрдә чирләүчеләр саны кимүен дә искәрткән.

Сәламәтлек саклау министры Михаил Мурашко исә 13 төбәктә коронавирус йоктыручылар өчен хастаханәләрдә ятак-урыннар санын арттыру, ковидка каршы чикләүләрне көчәйтү зарурилыгы турында белдергән. Министр әйтүенчә, аерым алганда, Удмуртия Республикасына, Смоленск, Ульяновск, Саратов, Самара өлкәләренә, Чуашстанга өстәмә чаралар кертү таләп ителә. Мурашко билгеләп үткәнчә, Россия субъектларында ковид йоктырган сырхаулар өчен 292 мең ятак-урын булдырылган. Бу – узган атнадагыга караганда 6 процентка күбрәк. Шул ук вакытта Россиядә 60 мең бала коронавирус белән чирли.

Сүз уңаеннан, Татарстанда узган тәүлек эчендә коронавирус йоктыруның 176 очрагы теркәлгән. 40 кеше – хастаханәдә, 136сы өендә дәвалана. 26 октябрьгә барлыгы 1441976 кеше прививка кадаткан, шуның 1010598е икенче дозасын алган.

Актуаль тема

Чират ялсыз эшли

КҮПФУНКЦИЯЛЕ ҮЗӘКЛӘРГӘ МӨРӘҖӘГАТЬ ИТҮЧЕЛӘР КИМЕМИ

Республикада булдырылган 60лап күпфункцияле үзәкнең болай да буш торганы юк иде. 11 октябрьдән соң эшләре тагын да артты. Мөрәҗәгатьләр күп, шуңа алар яллардан да баш тартырга мәҗбүр.

«Код бирегез безгә!»

Күпфункцияле үзәк ишеген ачарга күпчелекне менә шушы ихтыяҗ этәрә хәзер. Татарстан буенча күпфункцияле үзәкләр директоры Ленара Мозаффарова әйтүенчә, белгечләр барысын да аңлатырга, һәркемгә булышырга тырыша. Мөрәҗәгатьләр күп булу сәбәпле, аларга ялсыз эшләргә туры килә.

– Күпфункцияле үзәкләрдә чират җыела. Әйтик, 1 октябрьгә көненә 15 меңләп мөрәҗәгать кабул итсәк, шуларның 1300е – «Дәүләт хезмәтләре» порталында шәхесне раслау (потвержденная учетная запись ЕСИА. – **Ред.**) соравына кагылышлы була иде. 11 октябрьдән соң бу күрсәткечләр сизелерлек артты. Көненә 20 меңләп кеше килә, шуларның 8 меңләбе портал хезмәтләре сорауларына бәйле. 11–24 октябрь аралыгында шәхесне раслату өчен 109 меңгә якын мөрәҗәгать булды, – диде ул.

Шулай булгач, күпфункцияле үзәкләрнең ялсыз эшләми башка чарасы юк. Үзәк бүлекчәләрендә махсус кабул итү сәгатьләре дә барлыкка килгән. Бу вакытта хезмәткәрләр мөрәҗәгать итүчеләрнең бары тик порталда шәхесне раслау белән бәйле сорауларына җавап бирәчәк.

– Совет районы бүлекчәсе мисалында карасак, үзәкләр чәршәмбе һәм якшәмбедән кала кичке 5тән алып 8гә кадәр кабул итәчәк. Чәршәмбе – иртәнге 8дән 11гәчә, ә якшәмбе – иртәнге 8дән кичке 5кә кадәр кабул итү оештырылачак. 4, 6 һәм 7 ноябрьдә күпфункцияле үзәкләр ЕСИА сорауларына бәйле мөрәҗәгатьләрне иртәнге 8дән кичке 5кә кадәр кабул итәргә әзер, – дип аңлатты Ленара Мозаффарова.

Чиратта басып торырга теләмәгәннәр өчен, Ленара Мозаффарова мондыйрак киңәш бирде:

– «Дәүләт хезмәтләре» порталында теркәлү, QR-кодны бастыру өчен кич йә якшәмбе килү кулаерак. Бу вакытта кеше азрак була. Күпләр иртән йөри бит, шуңа зур чират барлыкка килә.

Кызганыч, парольне хәтерләмәү, телефон, паспорт, СНИЛС мәгълүматларын вакытында алмаштырмау кебек сәбәпләр порталда шәхесне раслау эшен шактый катлауландыра. 98 процент очракта хезмәткәрләргә барысын да ак биттән башларга туры килә икән.

Хезмәткәрләр димәктән, үзәкләрдә кадрлар кытлыгы да юк түгел. Кеше белән эшләү барысына да җиңел бирелми, әлбәттә. Хезмәткәрләр дә чирләми тормый. «Кешеләрне яратмасагыз, күпфункцияле үзәктә эшләү авыр булачак. Без студентларны да эшкә алабыз. Өйрәтәбез, әзерлибез. Яшьләргә сынау чорында 21 мең сум күләмендә хезмәт хакы каралган. Аннан, эшенә карап, хезмәт хакы да үзгәрәчәк. Әйтик, Әтнә районындагы белгеч көненә 3–8 кеше, Казандагысы 45әр кеше кабул итә икән, билгеле, матди хәлләре дә аерылачак», – дип аңлатты Ленара Мозаффарова.

Сораулар туган очракта Бердәм белешмә хезмәте телефонына шалтыратырга мөмкин. Аның номеры: 8 (843) 222-06-20.

Ахыры 2 нче биттә >

Татармын! Горурмын!

Ркаил ЗӘЙДУЛЛА, Татарстан Дәүләт Советы депутаты, халык шагыйре:

Сынатмастыр, сүрелмәстер күңел,
Дөрләр дә ул, балкып янар да.
Гаҗәп түгел, Тукай каны ага,
Татар каны ага тамырда.

(«Татар булып калыйк!» шигыреннән өзек)

ТАТАРСТАНДА – АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ

Гыйнвар – август айларында, узган елның шул ук чоры белән чагыштырганда, республикада терлекчелек тармагында җитештерү күләме арткан. Бу хакта Татарстанстат оешмасы хәбәр итә.

ИТКӘ ҖИБӘРЕЛГӘН ТЕРЛЕК ҺӘМ КОШ (тере килеш авырлыгы)
314,2 мең тонна / +1,7%↑

ЙОМЫРКА
1028,7 млн данә / +0,6%↑

СӨТ
1331,1 мең тонна +0,3%↑

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Дөньяда

СИРӘК МЕТАЛЛАР ТУДЫРГАН КӨРӘШ

Яңалыклар тасмасында дүшәмбе көнне Судан төп темага әверелде. Халкы ач һәм фәкыйрь булган бу Африка иле ни өчен бөтен дөньяның игътибарын җәлеп итә соң? Әйтик, ни өчен Вашингтонда бу илдәге хәлләр уңаеннан шулкадәр борчылалар һәм үткән атна ахырындагы түнтәрелештә Россияне гаеплиләр? Мәскәүдә, аңлашыла инде, кара континеттагы вәхшәтнең сценарием янкилар һәм көнбатышлылар яза дип баралар. Әле мәйданга тагын Төркия чыга. Эрдоган яңа гына: «Төркиянең Африкада ясаган һәрбер адымы континентны үзләренең арткы бакчалары дип санаган элекке колонизаторларны борчый», – дип белдерде. Вазгыятькә, әйдәгез, бер почмактан карыйбыз. Шуннан карасак, Әфганстандагы, өч Африка дәүләте – Үзәк Африка Республикасы, Мали һәм Судандагы хәлләрнең ни өчен кискенләшүен аңлау җиңелрәк булыр. Американың дәүләт департаментын да, французларны да, ярдәм итәбез дип, әлеге дәүләтләрдә хәрби контингентлар тоткан һәм корал саткан, кредитка батырган башка мәмләкәтләрне дә демократия мәсьәләсе борчымый, билгеле. Демократия дип йөрәкләре янса, алар Төньяк Кореяга бәреп керерләр, Мисырда хәрби түнтәрелеш ярдәмендә тәхеткә менгән режимны бәреп төшерерләр иде. Көнбатышны матди байлык, технологик киләчәк күбрәк кызыксындыра, энергетик ресурслар мәсьәләсе хәсрәтләндерә. Шул проблемалар алар файдасына хәл ителсә, «кеше хокуклары»н яклаучылар каннибаллар белән бер өстәл янында утыруга да каршы түгел.

Минем компьютерымда әле яңа гына Кытайдан килгән хәбәр ачык тора. Пекинда: «Дөньяга сирәк металлар (редкоземельные металлы) дефициты яный», – дип белдерәләр. Сүз уңаеннан әйтик, сирәк металлар базарын үз кулларында кытайлар тота. Әмма аларның чын хәзинәсе Африкада, Әфганстанда һәм Урта Азиядә. Җиңүдән соң Талибанның*: «Безнең илебез – Әфганстан – дөнья казылма байлыклары хәзинәсе… Әгәр аларны сәнәгать ысулы белән чыгарсаң, Әфганстан кебек йөз илне байлыкта яшәтеп булыр иде», – дигән белдерүләрен искә төшерик. Бу белдерүне мәгълүмат тасмасына чыгармадылар, әлбәттә, яшерделәр. Газета хәбәрчесе аны турыдан-туры Әфганстаннан алды. Тагын чиннарга әйләнеп кайтыйк. Алар әйтә: «Литий һәм кобальттан башка яшел энергетикага күчеп булмый», – диләр. Литий исә әфган туфрагында күмелеп ята. Югарыда без искә алган өч Африка иле дә андый байлыкларның өстендә утыра. Сирәк металларга бай тагын бер ил бар. Ул – Россия. Тик Россия әлегә аларны чыгармый диярлек, читтән сатып ала. Менә шуларны белгәч, ни өчен өч төрле көч: Көнбатыш, Россия һәм Төркиянең соңгы айларда, бер-берсен гаепли-гаепли, әлеге өч Африка дәүләтендә тартыш алып барулары аңлашыла. Кытай Әфганстан байлыкларына инвестицияләр ясарга җыена, Африкада да аның йогынтысы көчле, инвестицияләре якланган. Әфганны талиблар** кулына бирүнең дә бер сере шунда. Алардан башка илдә тәртип урнаштырып булмады бит инде. Тәртип юк икән, инвестицияләрне кем яклый һәм саклый? Көнбатыш, Россия, Төркия һәм Кытайның технологик ихтыяҗлар өчен сулар һава кебек кирәк булган табигый байлыкларны бүлешергә тырышуы дәүләт түнтәрелешләре генә түгел, Бөтендөнья сугышы да китереп чыгарырга мөмкин. Гаскәрләр ул сугышның сызыгына тезелделәр бит инде.

*Талибан – Россиядә тыелган оешма.

**Талиблар – Россиядә тыелган оешма вәкилләре.

Россиядә

ИНФЛЯЦИЯНЕ НИЧЕК АВЫЗЛЫКЛАРГА?

Владимир Путин Хөкүмәт чиновникларына 1 ноябрьгә кадәр дөнья базарындагы азот ашламалар, металл продукциясе һәм азык-төлек бәяләренең тотрыксызлыгы Россиягә тәэсир итмәсен өченниләр эшләргә икәнен уйлап табарга кушты. Димәк, якындагы көннәрдә бәяләрнең яңа күтәрелеше көтелә һәм моңа дөнья базарындагы хәлләр гаепле дип күрсәтелә. Инфляцияне импортлау дигән нәрсә бар инде ул үзе барын. Чит илләрдәге дефицит һәм бәяләр күтәрелеше безгә дә бик каты итеп суга. Азот ашламаларына бәя күтәрелү турында вице-премьер Новак чаң сукты. Ул Европада аммиак җитештерүче куәтләрнең 50 процентты тукталуы һәм азотлы ашламаларга бәяләрнең ике тапкыр үсүе, моның бездә дә азык-төлек бәясен күкләргә чөячәге турында сөйләп югарыдагыларны ваемсызлык йокысыннан уятырга тырышты. Әмма безнең үзебездә ул тышкы проблемалардан башка да ризык бәяләре чәчләрне үрә торгызырлык булып ята бит. Карабодайның болай да яныңа якын килерлек түгел иде, аңа тагын бәя өстәргә җыеналар, имеш. Башка ашау кирәге дә кимен куймый. Аңа тагын чит базарлардагы ашлама бәясе дә үз өлешен кертсә, чыдарлык булмаска мөмкин. Моны Кремльдә яхшы аңлыйлар. Күрәсең, Үзәк Банкның төп ставканы күтәрүе һәм тагын күтәрәчәге эшкә булышасына ышанып бетмиләр.

«Российская газета» үзенең соңгы санында без кичә әйткән фикерне кабатлый. Процент ставкасын күтәрү бәяләр үсешен туктатмый, көчәйтә генә, ди. Тәрҗемәсез генә бирик әйдә. Икътисадчы Яков Миркин яза: «Высокий ссудный процент превышает рентабельность по ряду отраслей. Он сам по себе источник инфляции, включается в издержки производства». Без бу фикерне Миркинга караганда бер көн алдан әйттек.

«Российская газета» авторы инфляцияне ничек туктатырга дигән сорауга үзенчә җавап бирә. Ул нефть сатучы Россияне шулай ук «кара алтын» базарын кулында тотучы Норвегия белән чагыштыра да, норвегларда инфляция 4,1 процент кына, бездә 7,4 дип, норвеглар файдасына нәтиҗә ясый (еллык инфляция 7,4 процент кына булса, бу юлларның авторы барып Миркинны кочаклап-үбеп кайтырга акчасын кызганмас иде, тик, кызганыч, ул кәгазьдәге инфляция генә шул). Миркин әфәнде норвег инфляциясенең түбәнрәк булуын, аларда Үзәк Банк ставкасының 0 процент кына булуын әле генә 0,25 процентка күтәрелүеннән күрә. Шуңа күрә аларда ипотека 2–2,5 процент кына, ди. Бездә дә кредит арзанлы булса, бәяләрне йөгәнләп, инфляцияне авызлыклап булыр иде, ди.

Монысы да эшли торган фикер түгел инде аның. Язмасының башында ул башка Көнбатыш дәүләтләрендәге түбән, хәтта минуслы төп ставкалар турында яза. Әмма бит Европада һәм Америкада да бәяләр күккә аша соңгы вакытларда. Кремльдә инфляция шулардан бәреп керә дип борчыла башладылар бит инде. Шулай булгач, Миркин язмасын чүплеккә ташласак та, берни югалтмыйбыз. Бәяләрне йөгәнләүнең ысуллары бар ул, тик алар олигархларга һәм финанс мафиясенә китереп суга һәм файдаланып булмый. Хөкүмәт түрәләре 1 ноябрьдән соң Путинга ни дип җавап бирерләр икән, шуны көтик әйдә.

УҢЫШЛЫ НӘТИҖӘ ТЫНЫЧЛАНЫР ӨЧЕН СӘБӘП ТҮГЕЛ

tatarstan.ru

Фәрит Мөхәммәтшин моңа кадәр «Бердәм Россия» партиясенең төбәк иҗтимагый кабул итү бүлегенең халык мөрәҗәгатьләре буенча координаторы булып эшләгән Нина Котеневага рәхмәт белдерде. Әлеге вазыйфага Анастасия Исаева билгеләнде.

«Бердәм Россия» партиясенең Татарстандагы бүлеге утырышы узды. Анда Дәүләт Думасына сайлау йомгаклары буенча кайбер мәсьәләләр хәл ителде.

Татарстан «бердәмроссиялеләре» җитәкчесе Фәрит Мөхәммәтшин партиянең яңа әгъзаларына партбилетлар тапшырды. Шулай ук республика районнарыннан да партиянең яңа әгъзалары таныклыклар алды. Очрашуда искәртеп үтелгәнчә, «Бердәм Россия»нең Татарстандагы бүлеге интернет киңлекләрендә партия эшчәнлеген яктыртуга юнәлдерелгән «Онлайн-агитатор» проектын тормышка ашыру буенча лидерлар унлыгына кергән.

– Муниципаль берәмлекләрдә барлык партия оешмаларының эшен, шул исәптән сайлау кампаниясен оештыру буенча нәтиҗәле эшен бәяләү бу. Сезнең тырыш хезмәтегез ярдәмендә партиябез сайлаучыларның иң күп тавышын җыйды. Әмма тынычланып калырга сәбәп түгел бу. Алда безне катлаулы бурычлар көтә, эш темпын киметергә ярамый, – диде Фәрит Мөхәммәтшин.

Көн тәртибенә сайлаудан соңгы чорда кадрлар мәсьәләләре кертелгән иде. Дәүләт Советы депутаты Татьяна Ларионова, Дәүләт Думасына сайлануы сәбәпле, республика парламентыннан китте. Утырыш барышында «бердәмроссиялеләр» вакантлы урынны «Бердәм Россия Яшь гвардиясе»нең Татарстандагы лидеры Динар Бариевка тапшыру өчен тавыш бирде.

Моннан тыш утырышта Татарстаннан сайланган Дәүләт Думасы депутатларын муниципалитетларга билгеләү мәсьәләсе каралды. Аерым алганда, депутатлар Татьяна Ларионова һәм Елена Ямпольская Казанның Яңа Савин һәм Совет районнарына, Чаллы шәһәре, шулай ук Алабуга, Менделеевск һәм Спас районнарына билгеләнде. Депутатлар Айрат Фәррахов һәм Максим Топилин исә Казанның Киров, Мәскәү районнарында, шулай ук Апас, Буа, Югары Ослан, Чүпрәле, Яшел Үзән, Кайбыч, Кама Тамагы һәм Тәтеш районнарында эшләячәк.

Элемтәләр ныгый

Ислам дөньясы дәүләтләре белән хезмәттәшлек итү Татарстан өчен өстенлекле юнәлешләрнең берсе булып тора. Дәүләт Советы Рәисе, Россия Закон чыгаручылар советының Халыкара хезмәттәшлек проблемалары буенча комиссиясе рәисе Фәрит Мөхәммәтшин «Россия – ислам дөньясы: парламентара хезмәттәшлек» дигән темага багышланган видеоконференциядә шулай дип белдерде.

– Без «Россия – ислам дөньясы» стратегик фаразлау төркеме эшчәнлегенә сәүдә, чит илләрдән турыдан-туры инвестицияләр өлкәләрендә, ислам финанс системасы мәсьәләләрендә элемтәләрне үстерүче көч буларак карыйбыз, – диде Фәрит Мөхәммәтшин. Ул Россия Президенты кушуы буенча Татарстан Президенты Рөстәм Миңнехановның, стратегик фаразлау төркеме рәисе буларак, төркем эшчәнлегенә җитәкчелек итүен искә төшерде.

Парламент башлыгы әйтүенчә, хезмәттәшлек икътисади юнәлештә дә үсә. «Татарстанда 2009 елдан бирле үткәрелеп килүче «Россия – ислам дөньясы» халыкара икътисади саммиты күп яклы элемтәләрне ныгытуга ярдәм итә, – диде Фәрит Мөхәммәтшин. – Быел саммитта 64 илдән һәм Россиянең 41 төбәгеннән 5 меңгә якын вәкил катнашты».

Дәүләт Советы Рәисе басым ясап әйткәнчә, Россия төбәкләрендә Федерация Советының Ислам дөньясы дәүләтләре парламентлары берлеге белән хезмәттәшлек урнаштыру тәкъдимен хуплыйлар. Фәрит Мөхәммәтшин парламентларның берлектә эшләвенең Россия белән ислам дөньясы дәүләтләре арасындагы элемтәләрне үстерүгә зур өлеш кертәчәгенә ышанычын белдерде.

Парламент башлыгы коллегаларын киләсе елда республикада планлаштырылган мөһим чараларда катнашырга чакырды. Алар арасыннан ул Болгарда ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгын һәм Татарстанда ЮНЕСКО Бөтендөнья мирас комитетының 45 нче сессиясен үткәрүне аерым атап үтте.

Фәрит Мөхәммәтшин Ислам хезмәттәшлеге оешмасы дәүләтләренең парламентлары берлеге делегациясенең Россиягә визиты кысасында парламентчыларга безнең республикага да килергә тәкъдим итте. Парламент башлыгы әйтүенчә, Татарстан ислам дөньясы белән хезмәттәшлек итү тәҗрибәсе белән уртаклашырга әзер.

! Исегезгә төшерәбез: хәзерге вакытта Ислам хезмәттәшлеге оешмасына 57 ил керә. Шуның 45е – парламентлар берлеге әгъзалары. Оешма милләтара аңлашу, террорчылык һәм экстремистлыкка каршы көрәш кебек мәсьәләләрне карауны төп игътибар үзәгендә тота.

mfc16.tatarstan.ru

Чират ялсыз эшли

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Ничек кодлы булырга?

– QR-код ул – цифрлы штрих-код. Аны теләсә кайсы смартфон камерасы ярдәмендә танып була. Шушы кодта кешенең вакцина кадатуы яисә коронавирус белән чирләве хакында мәгълүмат урнаша, – диде Татарстанның дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмати технологияләр һәм элемтә министры урынбасары Илья Начвин. – QR-кодлы документ «Дәүләт хезмәтләре» порталында сезнең шәхси сәхифәгездә вакцинаның икенче дозасын алганнан соң пәйда була. Аны «Дәүләт хезмәтләре»нең махсус кушымтасыннан да алырга мөмкин. Моның өчен шәхесегез расланган булырга тиеш. Тик моны башкару өчен күпфункцияле үзәккә бару таләп ителми. Банкларның (Ак Барс Банк, Сбербанк, Тинькофф, ВТБ, Авангард һәм башка банклар. – **Ред.**) мобиль кушымталары аша бу эшне тиз арада башкарырга була. Шәхси сәхифәгезгә керә алмасагыз, 122 номеры буенча шалтыратып, кызыксындырган сорауларыгызны бирә аласыз. Шәхесегез расланып та, QR-кодыгыз килмәгән икән, прививка кадаткан медицина оешмасына барып, сезнең хакта мәгълүматны реестрга кертүләрен сорарга кирәк.

Министр урынбасары китергән мәгълүматларга карасаң, 11 октябрьдә «Дәүләт хезмәтләре» порталында 82324 кеше шәхесен раслаган. Хәзерге вакытта республикада яшәүче 2582324 кешенең шәхесе порталда расланган булып исәпләнә.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

КОЯШ СҮНДЕ...

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Өйләр селкенеп куйды

Дүшәмбе кичен тетрәткән шартлау нәкъ менә шушы картның фатирында килеп чыккан да инде. Тикшерү комитетыннан алынган мәгълүматларга караганда, дүртенче каттагы фатирда бу ир-ат ялгызы гына яшәгән. Исерткеч эчемлекләр белән мавыккан, наркологта исәптә торган. 2010 елда ул газдан баш тарткан булган. Шуңа күрә плитәгә килүче газ торбасына металл томалагыч куйганнар.

Торак йорт шартлаганнан соң Чаллыда гадәттән тыш хәл режимы кертелде. Тикшерү комитеты әлегә фаҗигагә китергән өч сәбәпне карый. Күпфатирлы йорттагы шартлау газдан файдаланганда куркынычсызлык кагыйдәләрен үтәмәү, газ белән тәэмин итү буенча сыйфатсыз хезмәт күрсәтү аркасында килеп чыккан булырга мөмкин дип фаразлана. Владимир Рочев өзелгән газ торбасын үзлегеннән генә тоташтырырга маташкан дигән фараз да бар. Ник дигәндә, тикшерүчеләр картның фатирындагы газ торбасында тишек тапкан. Чаллы шәһәре буенча Тикшерү бүлеге башлыгы Евгений Викентьев сүзләренә караганда, хәзерге вакытта Россия Җинаять кодексының 238 маддәсе, 2 кисәге буенча җинаять эше кузгатылган.

Шартлау нәтиҗәсендә алты фатир җимерелгән, аларда 14 кеше яшәгән. Астагы өч катта урнашкан фатирларның тәрәзәләре чыгып очкан. Шартлау шулкадәр көчле була ки, хәтта күрше йорт диварларына кадәр селкенеп куйган.

– Фаҗига булган йорт бездән юл аша гына урнашкан. Өйдә тыныч кына чәй эчеп утырганда, бишенче унбиш минутлар тирәсендә көчле шартлау булды. Хәтта өй селкенеп куйды. Балконга йөгереп чыктым. Бер әйбер күренми. Шуннан күршем шалтыратып, күрше йортта шартлау булганын әйтте. Куркыныч, коточкыч хәл. Кешенең эштән кайта торган вакыты. Үзебез дә шул юл буйлап кибеткә, почтага барабыз. Балалар да шуннан йөри. Аллам сакласын! – ди каршы йортта яшәүче Гүзәл Шаһигәрәева.

Шартлау булган көнне фаҗига урынына Татарстан Премьер-министры Алексей Песошин да килде. Аның җитәкчелегендәге оператив штаб хезмәткәрләре фаҗига урынын тикшергәннән соң йорт подъездларына ишелү куркынычы янамый дип нәтиҗә ясады. Кичә шартлау булган урыннан 90 тонна җимерек калдыгы түгелгән. Татарстанның төзелеш министры урынбасары Ринат Абдуллин сүзләренә караганда, җимерелгән фатирларны торгызу өчен 2–3 ай вакыт таләп ителергә мөмкин.

Ярдәм булачак

Шартлау аркасында куышсыз калган кешеләр хәзерге вакытта җирле кунакханәгә урнаштырылган. Алар өчен барлык шартлар да тудырылган, җылы ризык белән тәэмин ителгән. Кайберләрен туган-тумачасы сыендырган. Хәзерге вакытта чит илдә яшәүче Дана Шаһиеваның әти-әнисе дә танышларында яшәп торырга мәҗбүр. Фаҗига булган подъездның беренче катында яшәгән алар. «Көчле шартлаудан соң җир тетрәгән кебек булган. Әти белән әни бер кат киемнән урамга чыгып йөгергән. Үзләре белән документлары да, дарулары да юк. Аларга кем дә булса ярдәм

nabchelny.ru

итәр дип уйламыйм. Шаулашырлар да туктарлар. Фатирны үзем төзекләндерәсе булыр инде. Моның өчен ким дигәндә ярты ел вакыт кирәк булачак», – ди Дана.

Чаллы шәһәре башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Илья Зуев исә фаҗигадә зыян күргән һәркемгә ярдәм итәчәкбез дип ышандыра. «Зыян күргән кешеләргә ярдәм оештырылды. Шулай ук йортның 11 нче подъездында һәм күрше подъездларда зыян күрүчеләр өчен финанс ярдәме чаралары да билгеләнәчәк. Йортның күрше подъездларында яшәп булу-булмау, кешеләрне фатирларга кертү мөмкинлеге ачыкланачак».

Фаҗига урынында Автозавод районы башлыгы Винер Харисов кизү тора. Аның сүзләренә караганда, биредә зыян күрүчеләргә ярдәм итү максатында оператив штаб оештырылган. Фаҗигале төннән соң икенче көнне иртүк бирегә ун кеше мөрәҗәгать иткән инде. «Хәзерге вакытта ишегалдында шәһәрнең социаль хезмәтләре эшли. Кемнең нәрсәгә мохтаҗ булуын сораштыралар. Зыян күрүчеләргә матди ярдәм билгеләү һәм бүлеп бирү өчен рәсми затлар билгеләнде. Без зыян күрүчеләр белән һәрвакыт элемтәдә», – ди ул.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

ТАТАРСТАН БЮДЖЕТЫ: БЕРЕНЧЕ УКЫЛЫШ

ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ДЕПУТАТЛАРЫ «2022 ЕЛГА, 2023 ҺӘМ 2024 ЕЛЛАР ПЛАН ЧОРЫНА ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БЮДЖЕТЫ ТУРЫНДА» ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ ПРОЕКТЫН БЕРЕНЧЕ УКЫЛЫШТА КАБУЛ ИТТЕ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕМЬЕР-МИНИСТРЫ УРЫНБАСАРЫ – ИКЪТИСАД МИНИСТРЫ МАРАТ ШАҺИӘХМӘТОВНЫҢ ПАРЛАМЕНТ УТЫРЫШЫНДА ЧЫГЫШЫ

Сезнең игътибарыгызга 2022–2024 елларга Татарстан Республикасының социаль һәм икътисади үсеш фаразларын тәкъдим итәбез.

Татарстан Республикасының 2022–2024 елларга социаль-икътисади үсеш фаразы парламент тыңлауларында, Дәүләт Советы комитетлары утырышларында, зона киңәшмәсендә җентекләп каралды.

Хәзерге вазгыятьне, икътисад үсешенең тышкы һәм эчке факторларын исәпкә алып, макроикътисади күрсәткечләр фаразы дәүләт финансларының баланслы булуына, бюджетны формалаштыруга турыдан-туры йогынты ясый. Дөнья икътисадында икътисади һәм эпидемиологик факторларга бәйле булган үсеш траекториясе билгесез булып кала. Глобаль икътисадтагы хәлләр тотрыксыз булып, дөнья базарларында катлаулы процесслар барса да, Россия икътисады кризиска кадәрге дәрәҗәсенә чыга алды.

Ил икътисадын торгызу, иң беренче чиратта эшкәртү сәнәгате, төзелеш секторы, сәүдә өлкәсендәге күләмнәрне арттыруга бәйле. Әлеге факторлар Татарстан Республикасының тулай төбәк продуктын үстерү өчен дә төп фактор булып тора. Республика һәм ил икътисады структурасында, тулаем алганда, иң зур чагыштырма авырлык сәнәгать җитештерүенә туры килә.

Дүртенче кварталда сәнәгатьтә, беренче чиратта нефть продуктлары һәм машина төзелешендә, предприятиеләр тарафыннан арттырырга планлаштырган күләмнәрне исәпкә алып, ел нәтиҗәләре буенча сәнәгать җитештерүе индексы 105,4% дәрәҗәсендә бәяләнә.

Быелгы аномаль һава шартлары республиканың авыл хуҗалыгы күрсәткечләренә тискәре йогынты ясады. Бу ел нәтиҗәләре буенча авыл хуҗалыгы продукциясенең күләме чагыштырмача бәяләрдә 81,7% дәрәҗәсендә көтелә, үсемлекчелек өлкәсендә – 65,2%, терлекчелектә – 99,2%.

Республиканың төзелеш секторындагы үсеш темпы – 103,7%.

Подряд эшләрен арттыру төзелеш материалларын җитештерү күләменең дә артуына китерде.

Кулланучылар базарында республикада ваклап сату әйләнеше үз хәленә кайтты.

Болар белән беррәттән, түләүле хезмәтләр күрсәтү һәм җәмәгать туклануы өлкәсендә бездә дә, тулаем ил буенча да, кризиска кадәрге дәрәҗәгә ирешеп булмады.

Коронавирус инфекциясе таралган шартларда Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә Россия Хөкүмәте тарафыннан бизнеска ярдәм итү буенча кризиска каршы чаралар кертеләчәк. Бу – бер тапкыр хезмәткә минималь түләү күләмендә грантлар һәм зыян күргән тармаклардан, шул исәптән җәмәгать туклануы өлкәсенә караган бизнеска ярдәм итүгә юнәлдерелгән 3.0 ФОТ программасын яңартып җибәрү.

Россия Хөкүмәтенең тиешле карарлары якын арада кабул ителергә тиеш.

2020 елгы пандемия чорында эшләү тәҗрибәсен исәпкә алып, муниципаль берәмлекләргә тармак министрлыклары, федераль салым хезмәте идарәсе, банклар белән берлектә һәр гариза буенча ярдәм күрсәтү чаралары турында бизнеска максималь дәрәҗәдә мәгълүмат бирүне тәэмин итәргә кирәк.

2021 ел нәтиҗәләре буенча предприятиеләрнең агымдагы тенденцияләрен һәм планнарын исәпкә алып, республиканың тулай төбәк продукты 2 трлн 907,8 млрд сум дип бәяләнә яки узган елгы бәяләр белән чагыштырганда 103,8 процентны тәшкил итә.

Татарстан Республикасының социаль-икътисади үсеш фаразын әзерләгәндә, билгеләнгән тәртип нигезендә, төбәкләр өчен ил хөкүмәте тарафыннан тәкъдим ителгән Россия икътисадын үстерүнең сценарий шартлары исәпкә алынган.

Республиканың социаль-икътисади үсеш фаразы күрсәткечләре республикада сәнәгать җитештерүенең 70 процентын формалаштыра торган предприятиеләрнең һәм оешмаларның белешмәләрен, тармак министрлыкларының, муниципаль берәмлекләрнең үсеш фаразларын, шулай ук ил үсешенең илкүләм максатларына ирешү буенча чараларны гамәлгә ашыруны исәпкә алып формалаштырылган.

Макроикътисади күрсәткечләр динамикасы даими игътибар үзәгендә тора. Бюджет турындагы законны кабул итү этабында да, аны үтәү барышында да вакытында һәм оператив җавап бирү өчен бу бик мөһим.

Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Нургали улы Миңнеханов үзенең Юлламасында тотрыклы икътисади үсешне тәэмин итү буенча агымдагы этапта төп бурычны билгеләде.

2022 елда тулай төбәк продуктының үсеш темпы түбәндәгечә фаразлана.

Әлеге үсешнең 35 проценты – сәнәгать җитештерүенә туры килә, 19 проценты – авыл хуҗалыгы, 17 проценты – сәүдә, 6 проценты – төзелеш.

Быел һәм киләсе елларда яңа җитештерү куәтләре кертү, эш күләмен арттыру хисабына һәм база тармакларындагы предприятиеләрдә яңа төр продукция чыгаруны исәпкә алып, сәнәгатьтә үсеш планлаштырыла, әлеге предприятиеләрнең төп проектлары слайдларда күрсәтелгән.

Фараз буенча, 2022 елда сәнәгать җитештерүе индексының үсеше 3,4% тәшкил итәчәк, шуның 70 проценттан артыгы нефть, газ, химия комплексы предприятиеләре тарафыннан тәэмин ителәчәк.

2022–2024 елларда, предприятиеләрнең планнарын тормышка ашыруны исәпкә алып, сәнәгать җитештерүе индексы 104% дәрәҗәсендә планлаштырыла.

Татарстан Республикасы Президенты үзенең Юлламасында сәнәгать өлкәсендәге бурычларны билгеләде.

Аның беренчесе – нәтиҗәлелекне арттыру. Шул исәптән: хезмәт җитештерүчәнлеген арттыру, инновацияләр кертү, җитештерүне цифрлаштыру. Икенчесе – экспортны арттыру. Өченчесе – импортны алыштыру. Дүртенчесе – сәнәгать куркынычсызлыгы. Бишенчесе – кадрлар белән тәэмин итү.

Бу мәсьәлә буенча якын арада Куркынычсызлык советы булачак.

2022 елда авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерү, фараз буенча, агымдагы ел дәрәҗәсенә карата чагыштырма бәяләрдә 110,7% тәшкил итәчәк, шул исәптән үсемлекчелектә – 126%, терлекчелектә – 100 %.

2022–2024 елларда тармакның дәүләт программасы нигезендә авыл хуҗалыгы продукциясенең үсеш темплары 101,9% дәрәҗәсендә каралган.

Татарстан Республикасы Президенты үз Юлламасында авыл хуҗалыгы җитештерүенең нәтиҗәлелеген алга таба арттыру бурычын куйды.

Дым туплау һәм дым саклау технологияләре өчен мәйданны арттыру белән бергә, икътисадның бу секторында агроиминиятләштерү инструментларын активрак куллану актуаль бурыч булып тора.

Фаразланган чорда, инвестиция проектларын гамәлгә ашыруны исәпкә алып, азык-төлек сәнәгатендә үсеш темплары 104,3% дәрәҗәсендә каралган.

Тотрыклы санитар-эпидемиологик шартларда 2022 елда ваклап сату һәм җәмәгать туклануы әйләнеше үсеше 102,4% дәрәҗәсендә фаразлана.

Фараз хезмәт хакы һәм халыкның акчалата керемнәренең күздә тотылган үсешенә нигезләнә һәм ил буенча гомуми фаразга туры килә.

Илкүләм проектлар буенча төзелеш комплексында торак һәм инфраструктура төзелешен арттыру күздә тотыла – фараз елында уртача үсеш темплары 101,5% тәшкил итәчәк.

Торак төзелешендәге фараз буенча өч ел эчендә 8,5 млн кв. метрдан артык торак тапшыру күздә тотыла. Торак төзелеше белән беррәттән, подряд эшләре күләменең яртысыннан артыгы инвестиция проектларын гамәлгә ашыруга бәйле.

Төзелеш секторының фараз күрсәткечләре икътисадта чама белән 8 процентны тәшкил итә, аңа ирешү өчен эшне планлаштырылган вакытта гамәлгә ашыруны тәэмин итү мөһим.

Уңай инвестиция климаты булдыру һәм инвестицияләр җәлеп итүне тәэмин итү икътисади үсешнең төп факторларыннан берсе булып тора.

Илкүләм максатларга туры китереп, 2030 елга кадәр төп капиталга инвестицияләрнең реаль үсешен, 2021 ел белән чагыштырганда, 70 проценттан да ким булмаган күләмдә тәэмин итү таләп ителә.

2021 ел бурычы – 104,5% дәрәҗәсендә үсеш. Беренче яртыеллыкта бу күрсәткеч 111,8% тәшкил итте.

2022 ел бурычы – инвестицияләр үсешен 104,7 процентка яки 733 млрд сумга җиткерү.

Инвестицияләр үсешен тәэмин итү факторларының берсе – инвестицион климатны һәм эшкуарлык эшчәнлеген алып бару шартларын яхшырту.

2022 ел нәтиҗәләре буенча республика инвестицион климат торышының илкүләм рейтингында үзенең икенче урынын саклап кала алды.

Шул ук вакытта илкүләм рейтингның аерым күрсәткечләре буенча кимү күзәтелә.

Мәсәлән, бизнес бәяләвенчә, төзелешкә рөхсәт бирү, кадастр исәбенә кую өчен документларны килештерү сроклары, электр белән тәэмин итү челтәрләренә тоташтыру өчен этаплар саны арткан.

Хезмәт күрсәтү процессларын оптимальләштерүгә юнәлдерелгән чаралар «юл картасы»нда эшләнгән, расланган һәм республиканың җаваплы министрлыкларына, ведомстволарына һәм оешмаларына беркетелгән. Аларның вакытында һәм сыйфатлы үтәлешен тәэмин итәргә кирәк.

Бу мәсьәлә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты утырышында җентекләп каралды, аның нәтиҗәләре буенча, илкүләм рейтинг күрсәткечләре нигезендә инвестицион климат торышын яхшырту чараларын гамәлгә ашыру турында республика Хөкүмәте карары кабул ителде.

Ике махсус икътисади зона инвестицион инфраструктураның төп элементы булып тора. Фаразланган чорда инфраструктура үсеше өлешендә дә, потенциаль резидентларны җәлеп итү өлешендә дә аларны алга таба үстерү планлаштырыла.

Инвестицияләрне үстерү факторларының берсе – моношәһәрләр территорияләрендә инвестицион проектларны гамәлгә ашыру.

Яңа резидентларны җәлеп итү, шулай ук эшләп торган предприятие-резидентларның тәкъдим ителгән бизнес планнар буенча яңа җитештерү егәрлекләренә чыгуын тәэмин итү бурычы тора.

Икътисади үсешне тәэмин итүдә республикада товар җитештерүчеләрнең сәүдә базарларын һәм экспорт потенциалын киңәйтү этәргеч фактор булып тора.

Россия Федерациясе үсешенең илкүләм максатлары турындагы указ белән ил Президенты тарафыннан 2030 елга чимал булмаган энергетика белән бәйле булмаган товарларны реаль экспортлауны, 2020 ел күрсәткечләре белән чагыштырганда, 70% дәрәҗәсенә этаплап җиткерү бурычы куелды.

Тулаем республика буенча 2022 елда экспорт күләме буенча максатчан параметр 11,3 млрд доллар тәшкил итә. Республика экспорты структурасында аның 70% чамасы нефть, нефть продуктлары һәм нефть химиясе продукциясе өлешенә туры килә.

Моннан тыш, бездә 1 млрд сумнан артык табышы булган һәм нульле экспорт күрсәткеченә ия сәнәгать предприятиеләре дә бар. Тармак министрлыклары белән берлектә, республика предприятиеләренә һәм оешмаларына экспортка дәүләт ярдәме чараларын куллану, федераль һәм төбәк үсеш институтлары, чит ил вәкиллекләре белән хезмәттәшлек итү, барыннан да элек, химия, машина төзелешендә, шулай ук хәләл индустриядә продукция чыгару дәрәҗәсен арттыру өчен мөмкин кадәр ярдәм итәргә кирәк.

Икътисадның нәтиҗәлелеген характерлаучы төп күрсәткеч ул – табыш. Быелның сигез аендагы нәтиҗәләр буенча табыш күләме – 410 млрд сумнан артык. Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк, кайбер тармаклар буенча икътисадның нәтиҗәлелеген арттыру һәм күбрәк табыш алу өчен резервлар бар. Республика икътисадында слайдта аерып күрсәтелгән тармакларның чагыштырма авырлыгы аларның табышка керткән өлешеннән шактый артып китә.

Тармак һәм муниципаль баланс комиссияләренең бурычы – һәр конкрет предприятие белән берлектә алар эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген һәм финанс нәтиҗәләрен арттыру буенча аерым юллар булдыру.

2021 елдагы тенденцияләрне исәпкә алып, икътисад күп яктан кече һәм урта бизнес үсеше белән бәйле. Кече һәм урта бизнес республика икътисадына өлеш кертүе белән берлектә, халык өчен эш урыннары да. Республикада эшли торган халыкның өчтән бер өлешеннән артыгы кече һәм урта эшкуарлык субъектларында эшли. Безнең алда 2022 елга әлеге күрсәткечне, үзмәшгуль гражданнарны да исәпкә алып, 707 мең кешегә җиткерү бурычы тора.

Эшләүчеләр санын арттыру өчен төп резерв булып сәнәгать паркларын үстерү тора.

Дәүләтнеке булсынмы, шәхсиме, аларны кимендә 70% дәрәҗәсендә тутыру бурычы бар. Бу авыллардагы эш урыннарының өстәмә үсешен тәэмин итәчәк. Татарстан Республикасы Президенты Р.Н.Миңнеханов тарафыннан килештерелгән сәнәгать паркларының нәтиҗәлелеген арттыру концепциясе нәкъ менә шул максат белән эшләнгән, аның кысасында резидентларга һәм идарәче компанияләргә төрле преференцияләрдән файдаланырга мөмкинлек бирүче закон инициативалары кабул ителде. Бүген Концепциягә илле сәнәгать паркы кертелгән. Хәзерге вакытта, аларга салым преференцияләре һәм дәүләт ярдәме чаралары бирү максатларында, идарәче компанияләр һәм сәнәгать парклары резидентлары белән килешүләр төзү һәм аккредитацияләү эше төгәлләнеп килә.

Бүген әлеге сәнәгать паркларында без резидентларның 15 яңа компаниягә артуын күзәтәбез, нәтиҗәдә әлеге паркларның уртача тулылану дәрәҗәсе 7 процентка артты. Шулай ук икенче кварталда эш урыннары 681гә арту күзәтелә. Бу эш муниципаль берәмлекләр белән берлектә дәвам иттереләчәк.

Кече һәм урта бизнесны үстерү өчен, җитештерелә торган продукциягә ихтыяҗ булдыру да – мөһим фактор. Шул ук вакытта электрон сәүдә өлкәсе зуррак әһәмияткә ия була бара. Хәзерге вакытта Татарстан Республикасында электрон сәүдәне үстерү буенча чаралар планы эшләнде, ул интернет-сәүдә инфраструктурасын үстерүгә, электрон сәүдә мәйданчыкларында товарны урнаштыру һәм алга этәрү буенча финанс һәм финанс булмаган ярдәм чаралары комплексы, шул исәптән халыкара сәүдә мәйданчыкларында урнаштыру, логистика, укыту, шулай ук махсус кредит продуктлары кебек бурычларны үз эченә ала.

Бизнеска, шул исәптән вебинарлар һәм консультацияләр үткәрү юлы белән дә, үз базарларын киңәйтү, шул исәптән экспорт өчен онлайн сәүдә мөмкинлекләреннән максималь файдалану өчен тулысынча ярдәм күрсәтеп, муниципаль берәмлекләргә, эшкуарларның хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилгә һәм тиешле республика хакимияте органнарына әлеге План үтәлешен тәэмин итәргә кирәк.

Үзмәшгульләрнең саны арту кече һәм урта эшкуарларда эшләүчеләр планын үтәүгә шактый өлеш кертә. Быел Татарстан Республикасында үзмәшгуль гражданнарга финанс һәм финанс булмаган ярдәм күрсәтүнең адреслы чаралары гамәлгә ашырыла.

Хәзерге вакытта үзмәшгуль гражданнарны 200 мең сумга кадәр субсидияләү программасына гаризалар кабул итү дәвам итә.

Татарстан Республикасы Президенты куйган бурыч – үзмәшгульләр үз эшен җәелдерсен һәм киләчәктә кече һәм урта эшкуарлык субъектлары буларак планлы рәвештә теркәлсен, өстәмә эш урыннары булдырсын өчен, ярдәм чараларының нәтиҗәлелеген арттыру.

Хөрмәтле депутатлар!

Нәтиҗәле икътисад халыкның социаль тотрыклылыгын һәм иминлеген тәэмин итү өчен нигез булып тора. Илкүләм максатларга ирешүне тәэмин итү кысасында реаль акча керемнәрен арттыру буенча максатчан план төзелде. 2022 елга республика буенча тулаем алганда индикаторның максатчан күрсәткече 103,1 процентны тәшкил итә. Гадәттәгечә, акчалата керемнәр структурасында аның 45 проценттан артык өлешен хезмәт хакы алып тора. 2022 елга реаль хезмәт хакын 102,7% дәрәҗәсендә арттыру планлаштырыла. Быелның гыйнвар – август ае нәтиҗәләре буенча уртача хезмәт хакы узган елның шул ук чоры белән чагыштырганда 11,6 процентка арткан.

Уңай инвестицион һәм эшкуарлык климатын формалаштыру, инвестицион проектларны гамәлгә ашыру, бизнеска ярдәм инфраструктурасын үстерү, аерым предприятиеләрдә дә, тулаем икътисад тармакларында да эшчәнлекнең нәтиҗәлелеген һәм хезмәт җитештерүчәнлеген арттыруга юнәлдерелгән.

Үземнең чыгышымда мин бу юнәлешләрне билгеләп үттем, һәм Комитетлар утырышларында без аларны җентекләп тикшердек. Моннан тыш, муниципаль берәмлекләргә керемнәрне легальләштерү буенча ведомствоара комиссияләр эшчәнлеге кысасында максатчан параметрларга ирешүне тәэмин итү һәм ачыкланган җитешсезлекләрне бетерү буенча тиешле чаралар үткәрү эшен дәвам итәргә кирәк. Бигрәк тә хезмәт хакы тармак һәм тулаем муниципаль берәмлек буенча уртача хезмәт хакыннан шактый түбән булган оешмаларга игътибар итәргә кирәк.

Фаразланган чорда, сценарий шартлары нигезендә, куллану бәяләре индексы узган елның декабренә карата 104 процентны тәшкил итәчәк.

Быелның сентябрь нәтиҗәләре буенча инфляция бераз тизләнде һәм узган елның декабренә карата 105,6 процентны тәшкил итә. Арту, бер яктан, эчке факторларга бәйле: әйтик, начар һава шартлары, терлекчелектәге чыгымнарның артуы, йөк ташуга бәяләр күтәрелүе, кулланучыларга кредит бирү динамикасы, шулай ук тышкы факторлар да бар: чимал һәм азык-төлеккә дөнья бәяләренең күтәрелүе, кризистан соңгы волатильлек, ихтыяҗның актив үсүе.

Кулланучылар базарындагы бәяләр торышын даими күзәтеп тору һәм икътисади җайга салу чараларын үз вакытында эшләп чыгару максатларында, куллана торган товарларга һәм күрсәтелә торган хезмәтләргә бәяләр динамикасын контрольдә тоту һәм анализлау буенча Хөкүмәт Карары белән җаваплы затлар беркетелде. Бәяләрнең инфляцияне арттырып үсүе ачыкланган очракта, республиканың җаваплы хакимият органнарына бәяләр динамикасына комплекслы анализ ясарга һәм тиешле йогынты чараларын эшләргә кирәк.

Төп бурыч элеккечә – барлык муниципаль берәмлекләрдә дә халыкны эш белән тәэмин итүне арттыру. Бу ел ахырына эшсезләр саны 20 мең кеше дәрәҗәсендә булыр дип көтелә.

Республика өчен илкүләм проектлар икътисад үсешенә өстәмә өлеш кертәчәк. Илкүләм проектлар өч юнәлеш буенча тормышка ашырыла: «Кеше капиталы», «Тормыш өчен уңайлы мохит» һәм «Икътисади үсеш».

Халыкның акчалата керемнәрен, төп капиталга инвестицияләрне, кече һәм урта эшкуарлык субъектларында эшләүчеләрне арттыру экспортны үстерү өлешендә аларның үтәлүенә тәэсир итә.

Билгеләнгән бурычларны үтәү максатында, җаваплы министрлыклар тарафыннан барлык планлаштырылган чараларны тормышка ашыру буенча федераль проект офислары белән тиешле эш алып барыла.

Хөрмәтле депутатлар!

2022–2024 елларга Татарстан Республикасының социаль-икътисади үсешен фаразлауның төп параметрлары әнә шундый. Фараз күрсәткечләренә ирешү өчен барлык дәрәҗәдәге хакимият, предприятие һәм оешмалар үзара килешенеп һәм координацияле эшләргә тиеш, килеп туган проблемаларның чишелеш юлларын ачыклау һәм икътисади үсеш резервларын билгеләү өчен оператив йогынты чараларын күрергә кирәк.

Игътибарыгыз өчен рәхмәт!

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫНЫҢ БЮДЖЕТ, САЛЫМ ҺӘМ ФИНАНС КОМИТЕТЫ РӘИСЕ ЛЕОНИД ЯКУНИННЫҢ ПАРЛАМЕНТ УТЫРЫШЫНДА ЧЫГЫШЫ

«2022 елга һәм пландагы 2023, 2024 еллар чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан кертелгән закон проекты Татарстан Бюджет кодексында күздә тотылган барлык күрсәткечләргә туры килә.

Өч елга керемнәр фаразы шушы чорга социаль-икътисади үсеш фаразы һәм бюджет, салым сәясәтенең төп юнәлешләре нигезендә булдырылган.

Комитетта билгеләп үтелгәнчә, проектта бюджет сәясәтенең барлык төп бурычлары күздә тотылган. Болар:

– республика бюджеты системасының озак вакытка тиешле балансын һәм тотрыклылыгын тәэмин итү;

– халык алдындагы социаль бурычларны, һичшиксез, үтәү;

– илкүләм үсеш максатларын тормышка ашыруда катнашу;

– барлык дәрәҗәләрдәге бюджетларның ачыклыгын һәм «үтә күренмәлелеген» тәэмин итү.

Беренче укылышка кадәр бюджет проектын карап тикшерү буенча барлык процедуралар тәмам.

Проект буенча җәмәгатьчелектә бик күп фикер алышулар үткәрелүен басым ясап әйтәсем килә. Башлангыч мәгълүматларга караганда, агымдагы елның 6 октябреннән бирле үткәрелгән чараларда иҗтимагый берләшмәләрдән 800дән артыграк вәкил һәм гражданнар катнашкан. Татарстан Республикасы Дәүләт Советына үткән сәяси партияләр вәкилләре үзләренең тәкъдимнәрен җиткергән.

Комитет парламент тыңлауларында ирештерелгән барлык тәкъдимнәрне Татарстан Республикасы Хөкүмәтенә юллады.

Проектның үзенчәлекләре:

– аны үтәү пандемиягә каршы көрәш шартларында дәвам иттереләчәк, шуңа күрә проект оптимальләштерелгән. Хөкүмәтнең Резерв фонды берникадәр арттырылган һәм кирәкле финанс ресурслары салынган;

– социаль юнәлешлелеге 80 процент чамасы тәшкил итә, аны планда каралган чорда алга таба да үстерү күздә тотыла;

– киләсе ел бюджеты программалы булып кала, бу республика территорияләрен үстерү эшен дәвам иттерү, иң мөһим ихтыяҗларга (торак, юллар, сәламәтлек саклау, коммуналь өлкә һ.б.) капиталь средстволар җибәрү мөмкинлеге бирәчәк.

Бюджетның программаларда күздә тотылган чыгымнарының төп күләме «кеше капиталы» юнәлешенә туры килә, бу – Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнехановның Дәүләт Советына еллык Юлламасында игълан иткән социаль-икътисади үсешнең төп юнәлешләренә аваздаш.

Шуны да билгеләп үтәргә кирәк: проект керемнәрне агымдагы елга расланган күрсәткечләрдән – 20 миллиард сумга, чыгымнарны 24 миллиард сумга арттыруны күздә тота.

Бюджет чыгымнарының иң зур өлеше «Мәгариф» (барлык чыгымнарның 22,5 проценты), «Социаль сәясәт» (18 процент), «Сәламәтлек саклау» (10,1 процент) бүлекләренә туры килә.

Коронавирус инфекциясенә бәйле чикләүләр йогынтысының 2022 елда да икътисадка зыян салу ихтималын күздә тоту зарурилыгы сүзсез дә аңлашыла. Шуңа күрә бюджет проектына халыкка һәм республика икътисадына ярдәм итү буенча өстәмә чаралар кертелгән.

Шул рәвешле бюджет классификациясенең җиде бүлеге буенча, шул исәптән әйләнә-тирә мохитне саклау, мәдәният һәм кинематография, сәламәтлек саклау, гомумдәүләт мәсьәләләре, икътисад бүлекләре буенча бюджет чыгымнары арттырылган.

Салым керемнәре бюджетны тиешле балансдка китерүдә төп рольне уйный, аларның динамикасы башлыча бөтен икътисади вазгыятьне гәүдәләндерә. Шуңа күрә аларны туплау, бюджетның һәр сумыннан нәтиҗәле файдалану эшен дәвам иттерергә кирәк.

Агымдагы елда гамәлдә булып килүче салым ташламаларының сакланып калуын билгеләп үтү мөһим.

Кешеләрнең тормыш сыйфатын яхшыртуга юнәлдерелгән илкүләм проектларны гамәлгә ашыру, элеккечә үк, бюджетның чыгым өлешенең өстенлекле юнәлеше булып тора. Моның өчен 25,7 миллиард сум, шул исәптән федераль бюджеттан 16,1 миллиард сум күздә тотылган. Бу акчаны сәламәтлек саклау, мәгариф, мәдәният өлкәләрен үстерүгә, яшәү өчен уңайлы мохит булдыруга җибәрү планлаштырыла.

Проектта шулай ук бурыч йөкләмәләрен, һичшиксез, үтәү, бурыч йөгенең республика бюджетына зыян китермәслек дәрәҗәдә булуын кайгырту күздә тотылган.

Чыгышымны йомгаклап, шуны әйтеп үтәсем килә: 2022 елга һәм пландагы 2023, 2024 еллар чорына бюджет тиешле балансдка китерелеп, бүгенге кыенлыкларны һәм Россия Федерациясе Президенты тарафыннан билгеләнгән илкүләм максатларны, шулай ук тотрыклы үсешне тәэмин итү чараларын исәпкә алып төзелгән.

Татарстан Республикасы Хөкүмәтенә һәм министрларга дәүләт программаларына үзгәрешләр керткәндә сайлау кампанияләре чорында сайлаучылардан алынган наказларны үтәүне күздә тотарга кирәклеген, аларның моны көтүен искә төшереп үтәм.

Ә Дәүләт Советы депутатларыннан, узган еллардагы кебек үк, бюджетны чынбарлыктан чыгып раслауларын сорыйм. Бюджет проектының барлык комитетлар һәм «Бердәм Россия» фракциясе тарафыннан хуплануын исәпкә алырга кирәк.

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФИНАНС МИНИСТРЫ РАДИК ГАЙЗАТУЛЛИННЫҢ ПАРЛАМЕНТ УТЫРЫШЫНДА ЧЫГЫШЫ

Республика Конституциясенең 94 нче һәм Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 61 нче маддәсе нигезендә Президент тарафыннан Дәүләт Советы карамагына киләсе 2022 елга һәм 2023–2024 еллар план чорына бюджет турында закон проекты кертелде.

Татарстан Республикасының бюджет турындагы закон проекты Россия Федерациясе Бюджет кодексы һәм Татарстан Республикасы Бюджет кодексы тарафыннан куелган таләпләргә туры китереп әзерләнде.

Закон проектын **22 маддә һәм 41 кушымта** тәшкил итә. Закон проектында Бюджет кодексы тарафыннан каралган документлар һәм материаллар бар. Документлар һәм материалларда бюджет формалаштыру барышын тулысынча чагылдырган мәгълүмат җыелды.

Бюджетны формалаштыру бер үк вакытта ике юнәлештә, ягъни керемнәр һәм чыгымнар өлешендә алып барылды.

Керемнәр күләмен санаганда, без, Финанс министрлыгы, Икътисад министрлыгы, Салым хезмәте, тармак министрлыклары, оешмалар белән бергә салымнарны исәпләдек. Шулай ук җирле бюджетларның керемнәре буенча без муниципаль берәмлекләрнең тәкъдимнәрен дә исәпкә алдык. Бюджетның чыгым өлешен әзерләү барышында республиканың министрлык һәм ведомстволарының, шулай ук муниципаль район һәм шәһәр берәмлекләренең тәкъдимнәре буенча киңәшмәләр уздырдык.

Уртак һәм бердәм эш нәтиҗәсендә, бюджет акчасын төп бүлүчеләр һәм муниципаль берәмлекләр белән сценар шартларда бюджет фаразы каршылыкларсыз килештерелде.

Шулай итеп, 2022–2024 елларга Татарстан Республикасы бюджеты, 45 муниципаль район һәм шәһәр берәмлеге, 911 авыл җирлегенең бюджеты төзелде. Муниципаль берәмлекләрнең барлык бюджетлары дефицитсыз фаразлана.

Алга таба – **бюджет керемнәре** турында.

Керем өлешен формалаштыруның сценар шартларын слайдта күрәсез.

Бюджетның керем өлешен формалаштыру республикабыз Икътисад министрлыгы тарафыннан эшләнгән Татарстан Республикасының социаль-икътисади үстерүнең төп күрсәткечләре нигезендә гамәлгә ашырылды.

Бер үк вакытта, бюджетны әзерләгәндә федераль законнардагы үзгәрешләрне дә исәпкә алдык. Аларның исемлеген экранда күрә аласыз.

Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан куелган республика икътисадына инвестицияләр җәлеп итү бурычын үтәү өчен, керемнәр буенча бюджет проектында гамәлдәге салым ташламалары һәм аларның кайберләренең планлаштырылган чорда дәвам итүе исәпкә алынды. Аларның исемлеген һәм күләмнәрен сез слайдта күрәсез.

Алга таба өчьеллык чорга **бюджетның керем чыганаклары** хакында тулырак сөйләп узам.

Чыгышта 2022 елга керемнәр һәм чыгымнарны атармын, 2023–2024 елдагы план чорына күрсәткечләр экранда булачак.

Табышка салым керемнәрен бәяләгән вакытта Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы мәгълүматларының «Табыш» күрсәткеченең күләм фаразы кабул ителде. Шулай ук республиканың эре һәм уртача оешмалары мәгълүматлары, салым хезмәте хисаплары һәм 2021 елның узган чорына салым җыелу динамикасы файдаланды. Табышка салымның гомуми күләменнән якынча 60 процентын тәэмин итүче предприятиеләр колачланды.

Нәтиҗәдә 2022 елда табышка салым 90,2 млрд сум күләмендә күтәелә.

Физик затларның керемено салым Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджетына 93,4 млрд сум күләмендә керер дип фаразлана. Республика бюджетына керемнәр 65,5 млрд сум тәшкил итәчәк. Салым буенча исәпләүләрне башкарганда Икътисад министрлыгы тарафыннан фаразланган хезмәткә түләү фонды, агымдагы елда керемнәрнең күтәелүче күләмен һәм аның фаразланучы чорда үсешен нигез итеп алдык.

Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджетына **акцизлар** кереме фаразы – 39,2, ә республика бюджетына 37,9 млрд сум тәшкил итә. Аларның товар төрләре буенча төзелешен Сез экранда күрәсез.

Киләсе салым – **оешмаларның мөлкәтенә салым**. 2022 елда аның буенча керемнәр 28,3 млрд сум күләмендә фаразлана. Планлаштырган вакытта төп капиталга инвестицияләр фаразы, салым хисабы мәгълүматлары исәпкә алынды.

Җир салымы – муниципаль берәмлекләр бюджетлары өчен әһәмиятле керем чыганагы. Салым буенча фаразны төзегәндә салым хезмәтләренең хисапларын исәпкә алдык һәм, әлбәттә, саннарны барлык муниципаль районнар һәм шәһәр берәмлекләре белән дә килештердек. Җир салымы кереме ел саен 8,1 млрд сум күләмендә фаразлана.

Транспорт салымы кереме 2022 елда 6,1 млрд сум күләмендә бәяләнә. Керемнәрне исәпләгән вакытта салым хисабы һәм берничә ел дәвамында җыелу күрсәткечләре исәпкә алынды. Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә транспорт салымы фаразланган күләмдә юл фондына күчереләчәк.

Бердәм керемгә салым – 17,9 млрд сум, республика бюджетына 11,9 млрд сум күләмендә фаразлана. Салым төзелешен Сез экранда күрәсез.

Тулысынча муниципаль берәмлекләрнең бюджетларына керүче **физик затларның милегенә салым** 2022 елда 2,4 млрд сум күләмендә бәяләнә.

Берләштерелгән бюджетның фаразланучы **салым булмаган керемнәре** күләме – 9,8 млрд сум, республика бюджетыныкы – 5,1 млрд сум. Бу күләмгә җир һәм милекне арендага бирүдән һәм сатудан, штрафлардан, экологик түләүләрдән һәм башкалардан табышлар керә.

Федераль бюджеттан **кайтарылмый торган керемнәр** Татарстан Республикасы бюджеты проектында 2022 елга 48,9 млрд сум күләмендә исәпләнгән. Федераль чараларның төзелеше слайдта күренә.

Алга таба – бюджет чыгымнары турында.

Берләштерелгән бюджетның чыгымнар күләмен санаганда, без федераль һәм республика дәрәҗәсендәге, хәзерге көндә гамәлдә булган законнарга һәм норматив-хокукый актларга нигезләндек. Чыгымнар Татарстан Республикасы Президентының Дәүләт Советына Юлламасында куйган өметле бурычларын тормышка ашыруга йөз тота.

Бюджет чыгымнарын сыйфатлаучы аерым юнәлешләрне билгеләп узам.

Беренче чираттагы, социаль әһәмиятле һәм агымдагы чыгымнар күләме елдан-ел арта бара. 2022 елга фаразланган бюджетта алар чыгымнарның барлык күләменнән якынча 80 процентын тәшкил итәчәк. Фараз күләме слайдта китерелде.

Чыгым өлешен санаганда, бюджет өлкәсендә эшләүчеләрнең аерым категорияләренә хезмәт хакын, икътисадта уртача хезмәт хакына кадәр арттыруга акчаны тулысынча салып калдырдык. Россия Президентының май аендагы Указларын тормышка ашыра башлаганнан бирле берләштерелгән бюджет чыгымнарының арта бару күрсәткечләре слайдта күренә.

Чыгымнарны дәүләт программалары буенча бүлү дәвам итәчәк. Бюджет чыгымнарының туксан проценттан артыгы программалар аша каралган. Илкүләм һәм федераль проектлар дәүләт программалары эчендә чагылыш тапты.

Социаль әһәмияткә ия булган республика чаралары инде берничә ел уңышлы гына финансланып килә. Киләсе елларда да бу мөһим чаралар дәвам итәчәк. Әлеге ассигнованиеләрнең гомуми күләме 2022 ел бюджетында 6,9 млрд сум тәшкил итәчәк. Аларның исемлеген сез экранда күрәсез.

Алга таба конкрет юнәлешләр буенча бюджет чыгымнары характеристикасы хакында.

Бюджет классификациясе нигезендә бюджетның чыгым өлеше **«Гомумдәүләт мәсьәләләре»** бүлегеннән башлана. Бүлек буенча 2022 елга берләштерелгән бюджет чыгымнары – 33,6 млрд сум, республика бюджеты буенча 26,9 млрд сум фаразлана. Бу бүлеккә Хөкүмәтнең резерв фонды чыгымнары; идарә аппаратын, Фәннәр академиясен һәм архивларны, мировой судьяларны тоту, авыл җирлекләренә грантлар тапшыру керә.

«Милли оборона» бүлеге буенча республика бюджеты чыгымнары 139,8 млн сум тәшкил итәчәк.

«Милли куркынычсызлык һәм хокук саклау эшчәнлеге» бүлеге буенча берләштерелгән бюджет чыгымнары – 1,9 млрд сум, республика бюджеты буенча – 1,3 млрд сум. Бу бүлек буенча Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы һәм аның чараларның, муниципаль берәмлекләрнең бердәм диспетчер хезмәтләренең эшен финанслау һәм башка чыгымнар күздә тотыла.

Берләштерелгән бюджет буенча барлыгы 69,5 млрд сум һәм республика бюджеты буенча 67,8 млрд сум белән **«Милли икътисад»** бүлеге үз эченә бер төркем тармакларны колачлый. Алар арасында иң эреләре – юл хуҗалыгы, капиталь характердагы чыгымнар, авыл хуҗалыгы, транспорт. Тармаклар буенча бүленешне экранда күрәсез.

«Торак-коммуналь хуҗалык» бүлегенең чыгымнары берләштерелгән бюджетта – 20,8, республика бюджетында 13,0 млрд сум күләмендә фаразлана.

«Әйләнә-тирә мохитне саклау» бүлегенең чыгымнары барлыгы – 5,9 млрд сум, республика бюджеты буенча 5,7 млрд сум күләмендә фаразлана. Әлеге чыгымнар табигатьне саклау чараларын гамәлгә куюга, Экология министрлыгы аппаратын, идарә тармагы учреждениеләрен тотуга тотыла.

Алга таба бюджет чыгымнарының иң эре бүлеге – **«Иҗтимагый-мәдәни өлкә»**.

Сез экранда күргән иҗтимагый өлкә чыгымнары сыйфатлары бу чыгымнарда ел саен үсеш динамикасы барлыгын күрсәтә. Социаль өлкә чыгымнары берләштерелгән бюджетта 2021 ел белән чагыштырганда 2024 елда 24,4 процентка үсә.

Иҗтимагый-мәдәни өлкәдә **«Мәгариф»** тармагы чыгым күләме буенча шактый зур. 2022 елда чыгымнар күләме берләштерелгән бюджетта – 109,8 млрд сум, республика бюджетында 68,7 млрд сум тәшкил итәчәк.

Бу чыгымнар исәбенә өстәмә рәвештә мәгариф учреждениеләренең яңа челтәре, укучылар контингенты артуы, кадет интернатларында тәрбияләнүчеләрне тоту, йомгаклау аттестациясен уздыруга чаралар керә.

«Мәгариф» тармагында республиканың бер төркем максатчан программалары финанслана. Алар арасында Татарстан Республикасында телләрне саклау һәм үстерү, балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру, белем бирү учреждениеләренә капиталь ремонт ясау, ресурс үзәкләрен булдыру программалары да бар.

Киләсе бүлек – **«Сәламәтлек саклау»**. Мәҗбүри медицина иминияте чараларын исәпкә алып, сәламәтлек саклауны тотуга һәм үстерүгә чыгымнарның гомуми күләме – 85,7 млрд сум, шул исәптән республика бюджетыннан 31 млрд сум тәшкил итәчәк.

Республика бюджетының сәламәтлек саклау өлкәсе чыгымнары эченә югары технологияле ярдәм, тармак учреждениеләрен тоту, даруларны һәм җиһазларны үзәкләштереп сатып алу, гемодиализ процедураларын уздыру, мәҗбүри медицина иминиятләштерү системасы аша медицина оешмаларын бер канал аша финанслау буенча чыгымнар керә.

Күләме буенча киләсе тармак – **«Социаль сәясәт»**. Чыгымнарның гомуми күләме биредә 55,4 млрд сум күләмендә фаразлана. Быел бирелүче барлык социаль пособиеләр һәм түләүләр инфляциягә карата арттырып саналган.

Алга таба 2022 елга – 17,3 млрд сум, республика бюджеты буенча 10,1 млрд сум күләмендә социаль өлкәнең киләсе бүлеге – **«Мәдәният, кинематография»** килә. Чараларны грантлар тапшыруга, китап фондларын туплауга, иҗади берләшмәләргә ярдәмгә, музейларны, театрларны, китапханәләрне, иҗади коллективларны тотуга юнәлтергә планлаштырыла.

«Физик культура һәм спорт» бүлеге буенча чыгымнар – 9,1 млрд сум, республика бюджеты буенча 3,8 млрд сум тәшкил итә.

Акчаны спорт әзерлеге учреждениеләре эшчәнлеген тәэмин итүгә, массакүләм спорт һәм спортта югары ирешүләр өлкәсендә чараларны оештыруга һәм уздыруга юнәлдерү планлаштырыла.

«Массакүләм мәгълүмат чаралары» бүлеге буенча 2022 елга республика бюджеты чыгымнары – 1,7 млрд сум, шул исәптән телерадиотапшыруларга – 991,6 млн сум, басма матбугатка һәм нәшриятка 701,5 млн сум күләмендә фаразлана.

«Муниципаль берәмлекләр бюджетларына гомуми характердагы бюджетара трансфертлар» бүлеге буенча республикада дотацияләр һәм башка гомуми характердагы бюджетара трансфертлар каралган, аларның гомуми күләме – 20,2 млрд сум.

«Дәүләт һәм муниципаль бурычка хезмәт күрсәтү» бүлегенең чыгымнары берләштерелгән бюджетта – 358,3 млн сум, республика бюджеты буенча 99,3 млн сум тәшкил итәчәк.

Шулай итеп, 2021 елга:

берләштерелгән бюджетның керем өлеше – 345,6 млрд сум, чыгым өлеше 356,5 млрд сум күләмендә фаразлана, дефициты – 10,9 млрд сум;

республика бюджетының керем өлеше – 305,7, чыгым өлеше 294,8 млрд сум фаразлана, дефициты – 10,9 млрд сум.

Киләсе слайдта Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджетының һәм республика бюджетының 2023 елга күрсәткечләре китерелгән.

Алга таба – 2024 елга мәгълүмат.

Хөрмәтле депутатлар!

2022 елга, 2023 һәм 2024 елдагы план чорына бюджет проекты Дәүләт Советы комитетлары утырышларында, парламент тыңлауларында, республиканың барлык район һәм шәһәр берәмлекләре белән киңәшмәдә тикшерелде.

Бюджетның төрле дәрәҗәләрдә җентекләп тикшерелүен исәпкә алып, хөрмәтле депутатларның закон проектын хуплауларын һәм аны беренче укылышта кабул итүләрен сорыйм.

Чыгышым тәмам.

Игътибарыгыз өчен рәхмәт.

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХИСАП ПАЛАТАСЫ РӘИСЕ УРЫНБАСАРЫ АЛЬБЕРТ ВӘЛИЕВНЕҢ ПАРЛАМЕНТ УТЫРЫШЫНДА ЧЫГЫШЫ

Хисап палатасы «2022 елга һәм пландагы 2023, 2024 еллар чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» закон проектына экспертиза үткәрде. Аның нәтиҗәләре буенча закон проектының закон таләпләренә, шул исәптән Бюджет кодексында билгеләнгән дәүләт бурычы күләменә һәм аны түләү чыгымнарына карата, дефицитның чик күләменә, Хөкүмәтнең Резерв фонды күләменә карата чикләүләр ягыннан туры килүе турында йомгак ясалды.

2022 елга төп салым керемнәре буенча күрсәткечләр республиканың социаль-икътисади үсеш фаразыннан, салым һәм бюджет законнары нигезләмәләреннән чыгып булдырылган.

Хисап палатасы, закон проекты нигезенә салынган мәгълүматларны тәфсилләп анализлау, фараз күрсәткечләренең нигезләнешен раслау максатыннан, Финанс министрлыгының, башкарма хакимият органнарының өстәмә мәгълүматларыннан файдаланды.

Кире кайтарылмый торган акча күләме учетының тулылыгын бәяләү өчен федераль бюджет проекты күрсәткечләре кулланылды.

Россия Федерациясе субъектлары бюджетларының федераль дәрәҗәдә трансфертларның тулы күләмендә билгеләнмәве шартларында булдырылуы сәбәпле, кире кайтарылмый торган акча күләме, алдагы еллардагы кебек, әлегә тәгаенләнмәгән.

Ел дәвамында өстәмә максатчан средстволар керәчәк. Шуңа күрә бу очракта бюджет законында билгеләнгән максатчан средстволарны чагылдыру һәм тоту механизмнары кулланыла.

Агымдагы ел бюджеты проектын формалаштыруда да шундый ук хәл кабатланган иде: кире кайтарылмый торган акча күләме кырык җиде миллиард сум күләмендә планлаштырылса, бүгенгә алтмыш бер миллиард сумнан артыграк күләмдә күздә тотыла.

Финанслашыла торган чыгымнар турында берничә сүз. Федераль бюджеттан субсидияләрнең гомуми күләме – агымдагы елга расланган күрсәткеч белән чагыштырганда алты миллиард сумнан күбрәккә артыграк.

Чыгымнарны арттыру күздә тотылган барлык юнәлешләр халыкка ярдәм итү һәм тормыш сыйфатын яхшырту өлкәсендә дәүләт сәясәтенең өстенлекле юнәлешләрен тормышка ашыруга бәйле. Мәсәлән, өч яшьтән җиде яшькә кадәрге балаларга түләүләр күләмен сизелерлек арттыру планлаштырыла.

Шулай ук балаларны бушлай тукландыруга, эчәргә яраклы су белән тәэмин итү объектларын төзү һәм реконструкцияләүгә, заманча шәһәр мохитен булдыруга средстволар күләме арттырыла.

Шуны билгеләп үтәргә кирәк: һәр субсидия буенча республика бюджетыннан финанслашу өлешләренең нисбәте үтәлгән.

Аерым юнәлешләр буенча республика өлеше, билгеләнгән өлеш күләме белән чагыштырганда, зуррак күләмдә планлаштырыла. Аерым алганда, ятимнәргә торак бирүгә республика бюджетындагы үзебезнең средстволар хисабына тәгаенләнүче чыгымнар федераль бюджеттан субсидияләр күләме кимүгә бәйле рәвештә арта.

Федераль дәрәҗәдә субъектлар бюджетларына җибәрелә торган средстволарны максималь дәрәҗәдә тәгаенләүне, аларны конкрет максатларга билгеләүне тәэмин итәрдәй ысул кулланылган. Бүгенгә закон проектында трансфертлар өлеше тулаем гына чагылдырылган. Финанс елы дәвамында бу средстволарга, бюджет классификациясенә туры китерүне тәэмин итү максатыннан, кирәкле максатчан кодлар биреләчәк.

Бюджет, алдагы еллардагы кебек үк, социаль юнәлешле. Гражданнарга социаль ярдәм чаралары сакланып кала. Инде алда билгеләп үтелгәнчә, бу максатларга ассигнованиеләр күләме арта, социаль инфраструктура объектларын төзү һәм төзекләндерү дәвам иттерелә.

Әлеге юнәлешләр илкүләм проектлар кысасында тормышка ашырыла, һәм алар Татарстан Республикасы дәүләт программаларына кертелгән. Бюджетны программа форматында формалаштыру илкүләм үсеш максатларына ирешүгә юнәлдерелгән, ул дәүләттән финанслауның нәтиҗәлелек индикаторларын күздә тота. Дәүләт программаларын үтәүне даими бәяләү һәм контрольдә тоту нәкъ менә шушы индикатор буенча хәл ителә.

Агымдагы елда Хисап палатасының республика Министрлар Кабинетына мөрәҗәгате буенча башкарма хакимият органнары дәүләт программаларын үтәүнең нәтиҗәлелеге күрсәткечләрен яңартты.

Шулай ук 2021 елда республика Хөкүмәте дәүләт программаларына кертелә торган барлык үзгәрешләргә экспертиза үткәрү буенча Хисап палатасы тәкъдимен хуплады. Безнең тәкъдим актив төстә тормышка ашырыла. Экспертизага алынучы документлар саны арта. Уртак эш, конструктив хезмәттәшлек үзгәртелә торган финанслау күләмнәренең куелган бурычлар һәм максатларга туры килүен саклауга ярдәм итә.

Закон проектында инвестицияләргә һәм капиталь төзекләндерүгә ассигнованиеләр тармаклар буенча бүленгән. Бу чараларны планлы нигездә үткәрү, чыгымнарны үз вакытында хәл кылу һәм көтелгән нәтиҗәгә ирешү өчен шартлар тудыра.

Муниципаль берәмлекләр белән бюджетара мөнәсәбәтләрнең финанс ягы буенча.

Закон проектында җирле бюджетларга трансфертлар күләме – 2021 елдагы белән чагыштырганда 11 процентка артыграк.

Муниципаль берәмлекләрнең үз вәкаләтләрен финанслашуга субсидияләр егерме бер миллиард йөз илле дүрт миллион сум күләмендә күздә тотыла.

Хисап палатасы бәяләмәсендә керемнәр һәм чыгымнар буенча, бюджетара мөнәсәбәтләрне финанс ягыннан тәэмин итү, һәр дәүләт программасын тормышка ашыруга ассигнованиеләр буенча җентекле мәгълүматлар урын алган.

Моннан тыш бәяләмәдә күрсәткечләрне үзгәртү динамикасына, аларның нигезләнешенә, керемнәрне проектлаудагы һәм чыгым йөкләмәләрен финанслаудагы тенденцияләр җентекләп анализланган.

Бу исә депутатлар тарафыннан киләсе чорга бюджет проектын карап тикшергәндә Хисап палатасының еллык докладының тирәнтен форматын билгели.

«2022 елга һәм пландагы 2023, 2024 еллар чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» закон проектына үткәрелгән экспертизаның төп нәтиҗәләрен әйтеп узасым килә:

1. Закон проекты бюджет проектын булдыру һәм аның эчтәлеге таләпләренә туры килә.

2. 2022 елга һәм пландагы чорга төзелгән бюджет – тиешле баланска китерелгән бюджет. Фараздагы керемнәр һәм дефицитны финанслау чыганакларыннан керемнәр планлаштырылган чыгымнар үтәлешен тулы күләмендә тәэмин итә.

3. Бюджет дефицитын үзебезнең финанслау чыганаклары тәэмин итә, алар закон таләпләренә туры килә.

КОТЛЫЙБЫЗ!

Һөнәри эшчәнлегендәге казанышлары һәм республиканың дәүләт хакимияте органнарында нәтиҗәле хезмәте өчен Татарстан Республикасы Президенты Эшләр идарәсенең гомуми бүлеге беркетмә секторы баш белгече **Бегутова** Эльмира Азат кызы, мәгариф системасын үстерүгә зур өлеш кертүләре һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре өчен «Казан милли тикшеренү технология университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесенең азык-төлек технологияләре көллияте директоры **Ильин** Анатолий Петрович, «А.Н.Туполев исемендәге Казан милли тикшеренү техник университеты – КАИ» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесенең физик культура һәм спорт кафедрасы профессоры **Йосыпов** Ринат Әндәрҗан улы, хореография сәнгатен үстерүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Муса Җәлил исемендәге Татар академия дәүләт опера һәм балет театры» дәүләт бюджет учреждениесенең балет буенча репетиторы **Прокопова** Валентина Васильевна; республиканың сайлау системасын үстерүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе аппаратының оештыру-методика бүлеге мөдире **Таҗиева** Фәридә Нуритдин кызы, мәдәниятне үстерүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының «Актаныш район мәдәният йорты» муниципаль бюджет учреждениесенең мәдәният чараларын оештыручысы **Хөсәенов** Инсан Галим улы, Кайбыч муниципаль районының социаль-икътисади һәм мәдәни үсешенә зур өлеш кертүе өчен Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы башлыгы **Рәхмәтуллин** Альберт Илгизәр улы **Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

***

«Таткоммунэнерго» республика җитештерү берләшмәсе» акционерлык җәмгыяте генераль директорының беренче урынбасары **Газизов** Марат Зөлфәт улына, Казан шәһәренең «Горводзеленхоз» су һәм агачлар-үсемлекләр утырту хуҗалыгы буенча шәһәр производство тресты» муниципаль унитар предприятиесенең агач-үсемлекләр утырту эшчесе **Гайнуллина** Илназ Илдар кызына, «ЖЭУ Профсервис» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры **Рәхимов** Вәсим Мәркасыйм улына, Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы урынбасары **Хәлилов** Радик Хамис улына **«Татарстан Республикасының атказанган торак-коммуналь хуҗалыгы хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

«АНГ-Холдинг» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры **Горшков** Алексей Николаевичка, «Керамик» акционерлык җәмгыяте мич вагонеткаларын төзекләндерү бүлекчәсенең футеровкачы-ташчысы **Зарипов** Рәдиф Нәкыйп улына, «РЕМОНТСТРОЙСЕРВИС» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең агач эше остасы **Куликов** Олег Игоревичка, «Яңарыш» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры **Сәлахов** Рәмзил Фәрвазетдин улына **«Татарстан Республикасының атказанган төзүчесе»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

«Казан шәһәренең азык-төлек һәм социаль туклану департаменты» акционерлык җәмгыяте 1 номерлы ашханәсе шеф-повары **Рыжманов** Сергей Александровичка **«Татарстан Республикасының атказанган халыкка хезмәт күрсәтү өлкәсе хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Җәмәгать куркынычсызлыгын тәэмин итүдәге, законлылыкны һәм хокук тәртибен ныгытудагы казанышлары өчен «Россия Федерациясе Федераль куркынычсызлык хезмәтенең Саратов һәм Самара өлкәләре буенча Чик буе идарәсе» федераль дәүләт казна учреждениесенең «Идел буе» чик буе контроле отрядының «Казан-аэропорт» контроль-үткәрү пункты башлыгы, подполковник **Афанасьев** Андрей Игоревич, «Җәзаларны үтәтү буенча федераль хезмәтнең Оператив бүлекчәләр эшчәнлеген тәэмин итү буенча баш идарәсе» федераль казна учреждениесенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе хезмәте аеруча мөһим эшләр буенча өлкән оперуполномоченные, эчке хезмәт полковнигы **Сәйфетдинова** Эльвира Кәримҗан кызы, Татарстан Республикасының мәдәни-рухи мирасын саклауга һәм баетуга зур өлеш кертүе өчен «Татар радиосы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең программалар алып баручысы **Мухина** Гөлназ Миңназыйм кызы **«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале** белән бүләкләнде.

***

Республиканың нефть сәнәгатен үстерүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Сервис НПО» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең 3 номерлы Лениногорск цехы электр җиһазларын төзекләндерү һәм аларга хезмәт күрсәтү буенча мастеры **Әкбәров** Илдар Газизҗан улы, «КРС-Сервис» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең ӘлмәтРемСервис предприятиесе йөк күтәрү механизмы машинисты **Максимов** Игорь Николаевич **«Өч миллиард тонна Татарстан нефтен чыгару уңаеннан» медале** белән бүләкләнде.

***

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының Кама буе территориаль идарәсе 2 разрядлы өлкән белгече **Гәрәев** Рөстәм Нургали улына, Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының Ык буе территориаль идарәсе 2 разрядлы өлкән белгече **Низамов** Таһир Гайнетдин улына **«Татарстан Республикасының атказанган экологы»** дигән мактаулы исем бирелде.

ҺИЧ ОНЫТАСЫМ ЮК

Диләрә Вәлиеваның шәхси архивыннан

БӘРӘКӘТЛЕ ГОМЕР КИЧЕРДЕК

Быелның октябрь ае ахырында халкыбызның сөекле улы, гармуннарда үзәк өзгеч итеп уйнаучы Рөстәм Вәлиевнең тууына 60 яшь тулган булыр иде. Ни кызганыч, сөеклебезнең бакыйлыкка күчүенә дә – җиде ел. Сагынмаган, юксынмаган көнебез юк.

Мин Рөстәм белән танышканда ул Габдулла Тукай исемендәге филармониядә, бөек җырчыбыз Илһам абый Шакиров бригадасында эшли иде. Минем исә Самара шәһәренең «Ялкынлы яшьлек» ансамбленә йөргән вакытым. Самара егете Рөстәм, җае чыккан саен, туган төбәгенә – әти-әнисе, туганнары янына кайта һәм һәр кайтуында диярлек «Ялкынлы яшьлек»не дә барлап чыга. Мин үзем – Азнакайда үскән кыз, Казанда медицина институтын тәмамлагач, яшь белгеч буларак, юллама белән Самарага җибәрелгән идем. Биюгә һәвәслегем ансамбльгә дә якынайтты. Эштән соң атнага өч тапкыр ансамбльгә килеп, үз телебездә аралашып, җырлап-биеп, канатланып кайта идем. Шулай бер көнне ансамблебез җитәкчесе Илгиз абый Колючев тиздән Самарага Илһам абый Шакиров бригадасы киләчәген әйтте. «Безнең Рөстәм дә кайта, алар белән очрашу оештырачакбыз», – диде.

Минем исә Илһам абыйның концертына бару күптәнге хыялым иде, шуңа да очрашуны көтеп тормастан, концертка билет алдым. Зал шыгрым тулы. Концерт «Совет Армиясе маршы» белән башланып китте. Илһам абый «Карурман»ны җырлап килеп чыгуга халык дәррәү торып басып, кул чабарга кереште. Өч сәгатькә якын барган концертта моң дәрьясына чумып, туган ягыма кайткандай булдым. Илһам абыйга өч баянчы уйнап торды. Шуларның берсе – Рөстәм белән Илһам абый якыннанрак таныштырды. «Бу егет – сезнең якташыгыз, бик талантлы, тәртипле, белемле егет», – диде ул һәм кулындагы чәчәк бәйләмнәрен аңа тапшырды. Озын буйлы, кабарып торган бөдрә чәчле гармунчы егет исә чәчәкләрен алдагы рәттә утырган ханымга бирде. Бу ханым Рөстәмнең әнисе икән, концертка әти-әнисе, барлык туганнары җыелып килгәннәр. Шул чакта: «Синең булачак ирең менә шушы Рөстәм инде», – дисәләр, мин аптырап калыр идем, чөнки сәхнә кешеләре, профессиональ артистлар минем өчен бөтенләй икенче дөнья кешеләре иде, гәрчә шигырьләр сөйләп, җырлап-биеп, спектакльләрдә уйнап үссәм дә.

Икенче көнне Илгиз абый вәгъдә иткән очрашу да булды. Очрашу азагында без үз осталыкларыбызны күрсәттек. Очрашу тәмамлангач, иптәш кызым һәм биюче егет белән өчәүләп чыгып киләбез, шунда Рөстәмгә юлыктык. Миңа карап: «Нинди чибәр кыз», – диде дә биюче егеттән: «Синең сеңлеңме әллә?» – дип сорады. «Юк», – дигән җавап бирелде. Икенче көнне ансамбль белән зур автобуска төялеп, Тольятти шәһәренә концерт куярга киттек. Рөстәм дә безнең белән барды. Юлда да, концерт вакытында да ул миңа карап-карап алса да, берни дә дәшмәде, яныма да килмәде. Юлда башка кызлар-егетләр белән уйнап-көлеп, шаярып барганлыгын хәтерлим. Соңыннан әйтүенчә, ул мине шулай күзәткән икән. Кире кайтканда автобуста һич уйламаганда-көтмәгәндә яныма килеп утырды, шуннан танышып-сөйләшеп киттек.

Рөстәмнең бертуган энесе Ренат та ансамбльдә бии иде, кайбер биюләрне без аның белән парлап та биедек әле, тора-бара: «Абый сиңа сәлам әйтергә кушты», – дип сәламнәр дә җиткерә башлады. Дуслыгыбыз көннән-көн ныгыды, хисләребез кәгазь битләренә төшеп, ике арада хатлар йөри башлады. Рөстәмнең хатларын мин гаиләбез ядкарьләре буларак саклыйм һәм әледән-әле укып, күзләрем яшьләнә. Аларда – яшәү мәгънәсе, тугрылык, киләчәккә өмет.

Өйләнешергә гаризаны Самара шәһәрендә биргән идек. Ләкин кибетләрдә кытлык заманы, безгә яраклы балдаклар таба алмадык. Балдакларны талонга Чаллы шәһәрендә юнәттек. Ә балдакка талонны исә Чаллыда язылышканнарга гына бирәләр икән. Без инде бу таләпкә риза идек. Туй исә Самарада Рөстәмнәр өендә узды. Рөстәмнең әтиәнисе, туганнары да мине бик җылы, үз кызлары кебек кабул иттеләр. Аллага шөкер, хәзерге көндә Рөстәмнең әнисе – Һәдия Вәлиулла кызы исән-сау. Аралашып яшибез. Ул миңа яратып «кызым» дип дәшә. Каенанам – көчле рухлы ханым. Күңелендә матур хатирәләрне яңартып, тормыш иптәше Шәрифулла, улы Рөстәм, кызы Гөлфия рухларына догаларын укып гомер итә. Кече улы Ренат һәрвакыт ярдәм итеп тора.

Улыбыз Ислам, кызыбыз Алиянең – үз гаиләләре. Әтиләре аларга һәрвакыт үрнәк булды, гадилеге, кешелеклелеге, ярдәмчеллеге аларга да күчте, оныкларыбызга да күчә бара.

Рөстәмебез матур, җуелмас эз калдырды. Халкыбыз аны, кайда гына гомер итсә дә, зарыгып көтеп алды, соклануын белдереп, рәхмәтләрен әйтеп озатып калды. Сәхнәдә дә, тормышта да матур, бәрәкәтле гомер кичерде.

Диләрә ВӘЛИЕВА

«Башыгызны эшләтегез!»



Бакчада тирләп-пешеп эшли торгач, аяк-куллар шактый арыганга, үзем җайлап әмәлләгән кәнәфигә килеп утырам. Бераз ял итеп алыйм, дим. Шунда төрле уйларга чумам. Чөнки баш арымаган, ул хәтта бөтен дөньяны онытып ниндидер гамәлләр кылганда да эшли-уйлый ала һәм уйларга тиеш тә.

Шунда, ял итеп утырганда, 60 ел элек университетта бер группада белем эстәгән сабакташым Миркасыйм Госманов искә төште. Ул безгә, Татарстан авыл-салаларыннан җыелган егет-кызларга, еш кына: «Башыгызны эшләтегез!» – дип куя иде.

Шунысы кызык: икенче курста укыганда ук ул үзебезнең укытучы профессорлар белән генә түгел, хәтта вакыт табып, Фәннәр академиясендәге тарихчылар, археологлар белән дә аралаша, шуңа күрә әлеге өлкәдәге проблемалар белән яхшы таныш иде.

Җәйге каникулларда барыбыз да авылларыбызга таралганда Миркасыйм университет һәм Фәннәр академиясендә тарихчы-археологлар төркеме белән йә Себергә, йә Идел буендагы борынгы татар дәүләте – Алтын Урда шәһәрләренә экспедицияләргә китә торган иде. Шуңа күрә инде ул бишенче курсларда университет тәмамлаганда үзе дә тарихны профессорлар хәтле белә иде. Аның кандидатлык диссертациясен бик иртә яклавы да очраклы түгел шуңа күрә. Озын сүзнең кыскасы, безнең чәчләребез карурман кебек шаулап торганда Миркасыймның башы тап-такыр булып калды. Менә шуңа күрә нык эшләгән башны тиле чәчләр бик иртә ташлап китә, күрәсең. Башын шәп эшләтә, инде 50 яшьләрдә тирән белемгә ия профессор-академик университетта проректор да булды, студентларга борынгы тарихыбыз турында лекцияләр дә укый башлады.

Әйе, башыңны ташка бәрсәң дә, нихәтле шәп эшләтсәң дә, группадагы 28 студентның барысы да галим булып китә алмыйдыр шул. Бер төркемнән 2 профессор-академик булса да бик яхшы бит инде. Әле бит төркемебездән Әзһәр Мөхәммәдиев дигән бик тырыш, чын талант иясе дә мәшһүр тарихчы-академик булып танылды. Төркемдәге тагын Котдус Дәүләтшин, Һәнүз Мәхмүтов, Илдус Гыйлаҗев кебек егетләребез дә тел-әдәбият галимнәре буларак, фән кандидатлары дәрәҗәсенә күтәрелделәр. Ә Наил Хәйретдинов белән мин фәкыйрегез район газеталары редакторлары, республика газетасының үзхәбәрчесе булып та эшләдек. Группабыздан шулай ук дистәләгән тел, әдәбият, тарих укытучылары да үсеп чыкты. Бер группа өчен аз түгел дип уйлыйм. Үзем редактор, типография директоры, район комитетында бүлек мөдире булып 47 ел хезмәт иткәннән соң ялга чыкканга да чирек гасыр. Әле бүген дә, шөкер, 85 яшемдә 4 газета, 2 журналга хәбәрләр язып торам.

Озын сүзнең кыскасы, Миркасыйм Госманов үзе генә түгел, без дә аның киңәшен тотып, башларыбызны эшләткәнбез, бүген дә эшләтеп торабыз.

Фарук НӘФИЕВ.
Тәтеш

Шәһитләргә бер дога

Репрессия җилләре безнең Купка авылын да читләтеп үтмәгән. Мостафа Габсәләмов, Хәсән Гарипов, Вәккас Гайнетдинов, Минемулла Ситдыйков гаиләләренә «кулак» ярлыгы тагылып, авылдан куылалар. Байтак гаилә куыласын сизенеп, үзләре авылны ташлап китәләр.

Әбием мәрхүмә сөйләве буенча, аларның гаиләсе дә шактый ук таза тормышлы була. Колхозлар оеша башлагач, Газизулла бабай ике атын, арба-тарантасларын, ургыч-суккычларын тапшырып, колхозга керә. Мәчкәрәдә мәдрәсә тәмамлаган бабай шул рәвешле «кулак»лыктан котылып калган. Бабайларның күршесендә яшәүче туганнары Гатиятулла абзыйлар исә колхозга кермәгән. Гатиятулла абзыйның Минебай исемле улын, колхозга каршы коткы тарата дип, биш елга концлагерьга җибәрәләр, гаиләсе исә, йорт-җирләрен ташлап, авылдан чыгып китә.

Солтанәхмәт мулла белән Шаһимөхәммәт мулла репрессия корбаннарының иң аянычлы язмышына дучар булалар. Аларның үлем җәзасына хөкем итәрлек нинди гаепләре булган икән соң? Бу сорау һаман да күктә асылынып калыр инде. Шулай интернетта утырганда бер документ күчермәсенә тап булдым. Ул – НКВДның 1937 елның 30 нчы июлендәге оператив боерыгы. Анда, репрессиягә эләккәннәр ике төркемгә бүленә, диелгән. Беренче төркемдәгеләр атылуга хөкем ителә, икенчеләренә 8–10 ел төрмә җәзасы каралган. Шулай итеп, авылыбызның ике мулласы беренче төркемгә керә, алар шәһит китәләр. Бу язмам исемнәре язып үтелгәннәрнең рухына дога булсын.

Миневасил ГАЗИЗОВ.
Кукмара районы

РӘХМӘТ ТӘ ИШЕТТЕК, КЫЕН ДА АШАДЫК

Артист кеше барысына да әзер булырга тиештер дип беләм мин. Шулай бер сезонда «Трибунал» исемле әсәр буенча куелган спектакльдә хыянәтче ролен бирделәр. Нинди роль икәнлеген исеме үк әйтеп тора инде.

Сиксәненче елның октябрь ае иде булса кирәк, Теләче районының Җөри авылында шушы спектакльне авыл халкына тәкъдим иттек. Шул тамашада минем хатын ролен уйнаучы артистыбыз: «Син ни йөзең белән немецларга сатылдың? Совет хөкүмәте безгә никельле карават бирде, ә син?» – дигән реплика әйтә. Мин тудырган образ чынлыкта партизаннар яклы, гаиләсе исә бу хакта ләм-мим, сатылган дип уйлыйлар. Репликага каршы мин: «Түү-тү инде ул совет власте», – дим. Менә шунда берәү сәхнәгә күтәрелде дә: «Син шулаймыни әле», – дип такмаклый-такмаклый муенга тондырды. Пәрдәне яптылар. Миңа кул күтәрүчене сөйрәп алып чыгып киттеләр. Әле яңарак кына солдаттан кайткан егет икән, бераз салмышрак та. Аңа карап спектакльне туктатмадык. Иртәгесен иртүк мине теге егет белән очраштырдылар. «Моны нишләтик соң, нинди җәза бирик?» – диләр. «Нинди җәза?! – мин әйтәм. – Образымны чынлап кабул итүенә рәхмәт аңа».

Бу очракта минем муенга тамызса да, уеныма бирелгән бәя бит инде ул.

Нуретдин НӘҖМИЕВ,
Татарстанның халык артисты

Сәяси партиянең, сәяси партиянең төбәк бүлегенең, кандидатның сайлау фондына средстволар керү һәм аларны тоту турында ЙОМГАКЛАУ ФИНАНС ХИСАБЫ

Сигезенче чакырылыш Россия Федерациясе Федераль Җыены Дәүләт Думасы депутатларын сайлау

«ЛДПР – Либерально-демократическая партия России» сәяси партиясенең Татарстандагы төбәк бүлеге

Татарстан Республикасы

Финанс хисабы юлы		Юл шифры	Сумма, сум	Искәрмә
1		2	3	4
1	Сайлау фондына алынган средстволар, барлыгы	10	0,00	
	шул исәптән			
1.1	Сайлау фондын булдыру өчен билгеләнгән тәртиптә алынган средстволар	20	0,00	
	шулардан			
1.1.1	Сәяси партиянең/сәяси партиянең төбәк бүлегенең/кандидатның үз средстволары	30	0,00	
1.1.2	Кандидатка үзен тәкъдим иткән сәяси партия бүлеп биргән средстволар	40	0,00	
1.1.3	Гражданинның ихтыяри иганә акчасы	50	0,00	
1.1.4	Юридик затның иганә акчасы	60	0,00	
1.2	22.02.2014 ел, N 20-ФЗ Федераль законның 71 статьясындагы 2, 4, 8 өлешләре һәм 12.06.2002 ел, N 67-ФЗ Федераль законның 58 статьясындагы 6 пункты нигезендә сайлау фондына алынган акча средстволары	70	0,00	
	шулардан			
1.2.1	Сәяси партиянең/сәяси партиянең төбәк бүлегенең/кандидатның үз средстволары, кандидатка үзен тәкъдим иткән сәяси партия бүлеп биргән средстволар	80	0,00	
1.2.2	Гражданинның средстволары	90	0,00	
1.2.3	Юридик затның средстволары	100	0,00	
2	Сайлау фондыннан кире кайтарылган акча средстволары, барлыгы	110	0,00	
	шул исәптән			
2.1	Федераль бюджет керемена күчерелгән	120	0,00	
2.2	Билгеләнгән тәртипне бозып алыну сәбәпле кире кайтарылган акча средстволары	130	0,00	
	шулардан			
2.2.1	Үзләренә иганәчелек тыелган яки түләү документында мәҗбүри мәгълүматларны күрсәтмәгән гражданнарга	140	0,00	
2.2.2	Үзләренә иганәчелек тыелган яки түләү документында мәҗбүри мәгълүматларны күрсәтмәгән юридик затларга	150	0,00	
2.2.3	Чик күләмнән артык дәрәҗәдә алынган средстволар	160	0,00	
2.3	Билгеләнгән тәртиптә алынган, әмма кире кайтарылган акча средстволары	170	0,00	
3	Тотылган средстволар, барлыгы	180	0,00	
	шул исәптән			
3.1	Сайлаучыларның имзаларын җыюны оештыруга	190	0,00	
3.1.1	Шулардан сайлаучылар имзаларын җыю өчен җәлеп ителгән затларның хезмәтенә түләүгә	200	0,00	
3.2	Теле-радиотапшырулар оешмасы аша сайлау алды агитациясенә	210	0,00	
3.3	Вакытлы матбугат басма редакцияләре аша сайлау алды агитациясенә	220	0,00	
3.4	Интернет челтәрендәге басмалар аша сайлау алды агитациясенә	230	0,00	
3.5	Басма һәм башка агитация материалларын чыгару һәм таратуга	240	0,00	
3.6	Гавами массакүләм чаралар үткәрүгә	250	0,00	
3.7	Мәгълүмати һәм консультация характерындагы эшләр (хезмәт күрсәтү) өчен түләүгә	260	0,00	
3.8	Килешүләр буенча Россиянең юридик затлары яки гражданнары тарафыннан башкарылган башка эшләр (күрсәтелгән хезмәтләр) өчен түләүгә	270	0,00	
3.9	Сайлау кампаниясен үткәрүгә турыдан-туры бәйле башка чыгымнарны хәл итүгә	280	0,00	
4	Фондның тотылмыйча калган средстволар калдыгының сайлау фондына күчерелгән акча средстволарына пропорциональ рәвештә бүленеше	290	0,00	
5	Хисап тапшыру датасына фондта калган средстволар (банк белешмәсе белән раслана) (стр.300 = стр.10 – стр.110 – стр.180 – стр.290)	300	0,00	

Сәяси партиянең, сәяси партиянең төбәк бүлегенең, кандидатның сайлау фондына средстволар керү һәм аларны тоту турында ЙОМГАКЛАУ ФИНАНС ХИСАБЫ

Сигезенче чакырылыш Россия Федерациясе Федераль Җыены Дәүләт Думасы депутатларын сайлау

«СПРАВЕДЛИВАЯ РОССИЯ – ПАТРИОТЫ – ЗА ПРАВДУ» социалистик сәяси партиясенең Татарстан Республикасындагы төбәк бүлеге

Татарстан Республикасы

Финанс хисабы юлы		Юл шифры	Сумма, сум	Искәрмә
1		2	3	4
1	Сайлау фондына алынган средстволар, барлыгы	10	5 736 250,00	
	шул исәптән			
1.1	Сайлау фондын булдыру өчен билгеләнгән тәртиптә алынган средстволар	20	5 736 250,00	
	шулардан			
1.1.1	Сәяси партиянең/сәяси партиянең төбәк бүлегенең/кандидатның үз средстволары	30	5 206 250,00	
1.1.2	Кандидатка үзен тәкъдим иткән сәяси партия бүлеп биргән средстволар	40	0,00	
1.1.3	Гражданинның ихтыяри иганә акчасы	50	530 000,00	
1.1.4	Юридик затның иганә акчасы	60	0,00	
1.2	22.02.2014 ел, N 20-ФЗ Федераль законның 71 статьясындагы 2, 4, 8 өлешләре һәм 12.12.06.2002 ел, N 67-ФЗ Федераль законның 58 статьясындагы 6 пункты нигезендә сайлау фондына алынган акча средстволары	70	0,00	
	шулардан			
1.2.1	Сәяси партиянең/сәяси партиянең төбәк бүлегенең/кандидатның үз средстволары, кандидатка үзен тәкъдим иткән сәяси партия бүлеп биргән средстволар	80	0,00	
1.2.2	Гражданинның средстволары	90	0,00	
1.2.3	Юридик затның средстволары	100	0,00	
2	Сайлау фондыннан кире кайтарылган акча средстволары, барлыгы	110	0,00	
	шул исәптән			
2.1	Федераль бюджет керемена күчерелгән	120	0,00	
2.2	Билгеләнгән тәртипне бозып алыну сәбәпле кире кайтарылган акча средстволары	130	0,00	
	шулардан			
2.2.1	Үзләренә иганәчелек тыелган яки түләү документында мәҗбүри мәгълүматларны күрсәтмәгән гражданнарга	140	0,00	
2.2.2	Үзләренә иганәчелек тыелган яки түләү документында мәҗбүри мәгълүматларны күрсәтмәгән юридик затларга	150	0,00	
2.2.3	Чик күләмнән артык дәрәҗәдә алынган средстволар	160	0,00	
2.3	Билгеләнгән тәртиптә алынган, әмма кире кайтарылган акча средстволары	170	0,00	
3	Тотылган средстволар, барлыгы	180	5 736 250,00	
	шул исәптән			
3.1	Сайлаучыларның имзаларын җыюны оештыруга	190	0,00	
3.1.1	Шулардан сайлаучылар имзаларын җыю өчен җәлеп ителгән затларның хезмәтенә түләүгә	200	0,00	
3.2	Теле-радиотапшырулар оешмасы аша сайлау алды агитациясенә	210	0,00	
3.3	Вакытлы матбугат басма редакцияләре аша сайлау алды агитациясенә	220	0,00	
3.4	Интернет челтәрендәге басмалар аша сайлау алды агитациясенә	230	535 000,00	
3.5	Басма һәм башка агитация материалларын чыгару һәм таратуга	240	1 667 694,30	
3.6	Гавами массакүләм чаралар үткәрүгә	250	0,00	
3.7	Мәгълүмати һәм консультация характерындагы эшләр (хезмәт күрсәтү) өчен түләүгә	260	315 165,70	
3.8	Килешүләр буенча Россиянең юридик затлары яки гражданнары тарафыннан башкарылган башка эшләр (күрсәтелгән хезмәтләр) өчен түләүгә	270	3 209 200,00	
3.9	Сайлау кампаниясен үткәрүгә турыдан-туры бәйле башка чыгымнарны түләүгә	280	9 190,00	
4	Фондның тотылмыйча калган средстволар калдыгын сайлау фондына күчерелгән акча средстволарына пропорциональ рәвештә бүлү	290	0,00	
5	Хисап тапшыру датасына фондта калган средстволар (банк белешмәсе белән раслана) (стр.300 = стр.10 – стр.110 – стр.180 – стр.290)	300	0,00	

Реклама

Җиңүчеләр 11 декабрьдә бүләкләнәчәк

«Болгар радиосы»ның IX Милли музыкаль премиясен тапшыру тантанасы 2021 елның 11 декабрендә онлайн форматта уза. Тантананы һәркем туры трансляциядә «Татарстан – Яңа гасыр» телеканалында, «Болгар радиосы» дулкынында һәм интернет киңлекләрендә күзәтеп бара алачак.

Премияне онлайн форматта уздыру радио өчен беренче тәҗрибә түгел. Билгеле булганча, эпидемиологик яктан катлаулы вазгыять аркасында 2020 елның музыкаль премиясе дә онлайн форматта узды. Узган елны онлайн концертны уртача 600 меңләп кеше караган. Тамашачылар арасында «Айфон» да уйнатылган иде. Быел да «Болгар радиосы» Милли музыкаль премиясе «Кайнар хит» җиңүчеләренә, зәвыклы җырчыларга «Алтын йолдыз» тапшыру белән генә чикләнми. «Болгар радиосы» гадәттәгечә яраткан тамашачыларын сөендерергә ниятли: туры трансляция барышында бүләк отып булачак.

Быел «Болгар радиосы»ның IX Милли музыкаль премиясендә 30га якын номинация булыр дип көтелә. Елдагыча әлеге премиядә популяр җырчылар катнаша, яшь җырчылар, «Кайнар хит» проектында җиңеп чыккан яңа башкаручылар белән дә танышып булачак.

«Болгар радиосы»ның Милли музыкаль премиясенең максаты – халык күңелендә үз урынын тапкан җырчыларны һәм җырларны барлап алтын фондка кертү. «Болгар радиосы» радио тыңлаучыларның фикеренә таянып, җырларның иң-иңнәрен генә сайлый. Легендар җырчыларның иҗатын саклау һәм яктырту белән беррәттән, яшь җырчыларны танытуга да үз өлешен кертә.

IX Милли музыкаль премиясе җиңүчеләре «Алтын йолдыз» белән бүләкләнәчәк!

«Болгар радиосы»ның IX Милли музыкаль премиясен тапшыру тантанасын 11 декабрьдә 18.00 сәгатьтә «Татарстан – Яңа гасыр» телеканалында, интернет киңлекләрендә карап һәм «Болгар радиосы» дулкынында тыңлап булачак.

Спорт

КАЗАННАН БЕРӘҮ ГЕНӘ

Россия җыелма командасы тренерлары ноябрь аенда узасы уеннарда чыгыш ясарга мөмкин булган футболчылар исемлеген игълан итте. Исемлеккә 41 уенчы кергән. Җыелма команда 11 ноябрьдә – Кипр, 14ендә исә Хорватиягә каршы уйнаячак. Шуның белән киләсе елда Катарда буласы дөнья чемпионатына сайлап алу матчлары тәмамлана.

Исемлектәге 41 футболчы арасында «Рубин»нан бер генә уенчы – сакчы Илья Самошников бар. Моңа кадәр җыелма командага капкачы Юрий Дюпин да чакырыла иде. Бу юлы исә аны алмаганнар. Дюпинның соңгы очрашулардагы уены, дөресен әйткәндә, мактап телгә алырлык түгел. Хәер, бу аңа гына түгел, «Рубин»га тулысынча кагыла. Казан командасы соңгы 10 очрашуда нибары бер мәртәбә җиңә алды. Шуңа күрә башкала клубында үзгәрешләр булу ихтималы турында сүзләрнең торган саен күбрәк ишетелүе гаҗәп түгел. Ник дигәндә, яхшы уенчылар җитәрлек, нәтиҗә исә күренми.

Җыелма командага килгәндә, баш тренер Валерий Карпин бу юлы исемлеккә 7 яңа уенчыны керткән. Алар арасында капкачылар Илья Лантратов («Химки»), Никита Хайкин («Будё-Глимт», Норвегия), сакчы Данил Круговой («Зенит»), ярымсакчылар Константин Марадишвили («Локомотив»), Александр Черников («Краснодар»), Роман Ежов («Крылья Советов») һәм һөҗүмче Иван Сергеев («Крылья Советов») бар. Шунысы кызык: Россия футболының төп һөҗүмчеләреннән саналган Артем Дзюба бу юлы да ил данын якламаячак. Сүз уңаеннан, ул әле узган атнада гына «Спартак» капкасына туп кертте һәм ил чемпионатларында иң нәтиҗәле ике уенчының берсенә әверелде. Олег Веретенниковның да, Артем Дзюбаның да 143әр голы бар.

Белдерү

Утерян вкладыш от диплома Казанского Государственного Технологического Университета на имя Валиулиной Лилии Ерулловны (ВСГ 2311831 номер 3-1068 от 06 июля 2009 года).

СА/ЫНАЛУ ЧОРЫ

Җанисәп – 2021

Ил күләмендә халык санын исәпкә алу дәвам итә. «ВТ» шул уңайдан танылган шәхесләрнең фикерләрен туплады.

vk.com

Рамил ТӨХВӘТУЛЛИН,
Татарстан Дәүләт Советы депутаты, халык артисты:

– Минемчә, халык санын алу – дәүләт өчен дә, халык өчен дә мөһим вакыйга. Дәүләткә ни өчен кирәк булуы аңлашыла инде: статистик мәгълүматларны яңарту демографик кына түгел, икътисади, сәяси яктан да әһәмиятле. Ә халык исә үзенең кайсы милләт вәкиле булуын яхшы аңларга, сорауларга аңлы рәвештә җавап бирергә тиеш. Бу билгеле бер милләтнең санын гына түгел, сыйфатын да күрсәтәчәк. Милли мәгариф нинди хәлдә – шуны ачыкларга ярдәм итәчәк. Ләкин илдәге киеренкелек кешеләргә җанисәп турында уйларга мөмкинлек бирәме икән? Кешене сәламәтлеге борчый, ул кибетләрдәге бәяләр артуга, ә хезмәт хакының кимүенә аптырый. Болай булганда, халык санын алу аның өчен беренче урында торамы икән соң? Минемчә, милләтпәрвәрлек хисе белән яхшы таныш булганнар гына бүген бу турыда уйлый аладыр.

Бүген татарларга шактый кыен. Чал тарихлы халыкны ничек кенә бүлгәләмиләр. Хәзер инде яшермичә тураклыйлар бит! Нигә нәкъ менә безнең бөтенлеккә кагылалар? Бу бит кешене бик нык бутый. Татарларга киртә коручылар җитәрлек. Ләкин, ничек кенә булса да, безнең халык – көчле ул. Тарихи хәтер исән, милли аң тирән. Безгә бары тик битараф калмаска гына кирәк.

Разил ВӘЛИЕВ,
Татарстанның халык шагыйре:

– Халык санын алуга кеше битараф карый. Нәрсә дип язсалар да ярый инде, аңа карап кына берни үзгәрми, диләр. Менә шушы фикерне ничек тә булса үзгәртәсе иде. Газета-журналлар, электрон матбугат чаралары ашамы, җанлы очрашулар уздырыпмы. Безнең халык – бөек халык. Зур тарихыбыз, әдәбиятыбыз, мәдәниятебез – һәммәсе бар. Һәм алар барысы да югары дәрәҗәдә. Ләкин безнең халыкның милли аңы тиешле дәрәҗәдә түгел. Нишләптер ул үз милләтенә күпмедер дәрәҗәдә битараф карый. Мин моны аңлый да, аңлата да алмыйм. Туган авылга кайткач та, милләт мәсьәләләре турында сөйләшә башласаң, кушылып китәрдәй кешеләр бик сирәк.

Бүген без – әдәбият, сәнгать әһелләре, укытучылар, мәгариф хезмәткәрләре халыкка үз тарихыбыз турында сөйләргә тиеш. Милли горурлыгы булмаган кеше милләтенә карата битараф була. Ә милли горурлык хисе булсын өчен кеше үзенең тарихын белергә тиеш. Билгеле, һәркем дә татар тарихының җиде томлыгын укып чыкмас, әмма ул һич югы халкының күренекле шәхесләрен белергә тиеш. Аларга сокланып, чыннан да, безнең халык бөек икән ул диярлек булсын. Менә шуны аңлатырга иде кешеләргә.

Милли аңны бер көндә генә яки халык исәбен алганда гына аңлатып бетереп булмас. Без киләчәкне күздә тотып та эшләргә тиешбез. Моның өчен милли мәгариф системасы тиешле дәрәҗәдә эшләргә тиеш. Әлегә ул эшләми. Монда Татарстан укытучылары, республиканың мәгариф хезмәткәрләре генә гаепле түгел, гомумән, мәгариф системасында татар тарихын өйрәнү юк дәрәҗәдә. Кабатлап әйтәм: кеше үз тарихын белми икән, ул нәрсә белән горурлансын? Ничек итеп ул, мин менә шушы бөек халыкның улы яки кызы, дип әйтә алсын?!

Зөлфия ВӘЛИЕВА,
Татарстанның атказанган артисты:

– Җанисәптә әле катнашырга өлгермәдем – яздыручының килгәнен дүрт күз белән көтәбез. Үзем катнашмасам да, ишетеп һәм күреп беләм: бу юлы җанисәптә яңа, вак сораулар бар икән. Ни дәрәҗәдә кирәкле икән алар? Бу нииндидер без белеп бетерми торган сәясәтме? Әлегә бу мәсьәлә бик аңлашылмый. Шуңа да бик яхшылап уйлагач кына җавап бирергә тырышырга иде.

Халык санын алуга исәпләнгән бу көннәрдә безгә бөтен көчебезне, аңыбызны, халкыбызга булган мәхәббәтне тупларга, бөтен дөньяга үзебезнең кем икәнне белдерергә кирәк. Күрсәтерлегебез бар бит! Татар тирәсендә нинди генә сүзләр йөрсә дә, безнең кыйблабыз юкка чыкмады әле. Сирәгрәк булса да, аңлы, сәләтле, милли җанлы яшьләребез бар. Аннан соң, тарихка гына күз салыйк: сынмадык бит, бу юлы да ятып калмабыз.

Эльмир НИЗАМОВ,
композитор:

– Халык санын алуда, әлбәттә, катнаштым. Бу – ил генә түгел, кешелек җәмгыяте өчен мөһим вакыйга. Дөнья үзгәрә, без дә үзгәрәбез. Аннан соң, җанисәп – үз фикереңне белдерү өчен дә яхшы мөмкинлек. Һәркем үзен нинди милләт вәкиле итеп тоя, шулай җавап бирергә тиеш. Без, татарлар, күпмегә артканбыз икән – минемчә, милләте турында уйлаган һәркемгә бу да кызыктыр. Сан сыйфатка күчә, дигән гыйбарә бар бит. Ул нәкъ менә бу очракка туры килә дә инде.

Луиза ЯНСУАР,
Кариев театры директоры:

– Агитацияләр, тарткалашуларны өнәмим. Без тарихи барышта һәм җирлектә төрле этапларны кичеп, төрле компонентлардан формалашып оешканбыз. Телебез ягыннан да, мәдәни-рухи кыйммәтләребез буенча да бер-беребезне хөрмәт итеп, бергә яшәргә, үсәргә һәм дөнья аренасында үзебезне затлы итеп күрсәтергә, ә иң мөһиме – булганны кадерли белергә кирәк.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

СОФИЯ ПЕРЕС:

«МИН – ТАТАР КУБИНКАСЫ»

София Пересны якыннары Суфия дип тә йөртә. Мулла кушкан исеме ул аның. Әтисе – Куба егете, әнисе – татар кызы. Татарстанга укырга килгән Лино Мөслим кызы Асияне бер күрүдә ярата. Кыз да үлеп гашыйк була. Яшьләр исә гаилә корып, Кубага китеп баралар. София шунда туа.

Үзендә әллә ничә төрле гореф-гадәт, милли традицияләр йөртә ул. Сөйләшкәндә дә бер генә телдә фикерен әйтеп җиткерә алмый. Үзе дә сизмәстән йә инглиз теленә, йә испанчага, йә русчага күчә. Безнең белән бик тырышып татарча сөйләште. Янәшәсендә 5 яшьлек кызы Мария-Бенита да бар. Сабый да әнисе кебек дүрт тел өйрәнеп килә. Матур итеп «әнием» дип тә эндәшә, «мама»га да күчә.

«Әтием әниемне бик ярата. Алар бишенче курста туй ясыйлар. Казанда мондый туйның үткәне булмый әле, мәҗлескә күп кеше җыела. Әбием дә, бабам да әнием сайлаган язмышына кысылмый, биш ел буе араларындагы мәхәббәтнең ныгуын күрәләр. Әтиемнең әни өчен өзелеп торуын аңлагач, өйләнешүләренә риза булалар. Мәхәббәт үзенекен эшли. Алар 1982 елда Кубага күчеп китә, – дип сөйли София. – Дүрт елдан мин дөньяга килгән. Әтием – хәрби кеше. Миңа ике ай булганда әтиемне интернациональ бурычын үтәү өчен Анголага җибәргәннәр. Ул анда ике ел хезмәт итә. Әнием исә хәрби-диңгез академиясендә курсантларга рус теле укыта. Әтием отставкага чыга да сәясәткә кереп китә. Шушы вакытта – Россиядә, аннан соң Кубада үзгәрешләр башлана. Әбием үлгәч, әни мине дә үзе белән алып Мөслимгә кайтып китә, әти исә Кубада кала. Хәрби булгач, аны илдән чыгармыйлар. Әнә шулай итеп, гаилә таркала. Авыр булса да, алар тату аерылыша. Гомумән, Кубада ир белән хатын аерылышканда балаларның психикасын бозып, тавыш куптарып йөрмиләр».

Мөслимдә озак яшәми алар. Софиянең әнисе балачак дусты Мулланурны очрата һәм яңа гаилә барлыкка килә. Бергәләп Азнакайга күченәләр.

– Мулланур абыйга әти дип йөри башладым, ул мине бик яратып үстерде. Мулланур әтием кара-кучкыл тәнле, бөдрә чәчле иде. Бик күпләр мине аның кызы дип уйлый иде, – дип сөйли София. – Үз әтием белән мин 9 нчы сыйныфны тәмамлагач очраштык. Әтием Лино без Кубадан кайтып китәр алдыннан әниемә, берәр кайчан кызымны миңа күрсәтергә вәгъдә бир, дип озатып калган булган. Хәрби булгач, илдән чыга алмаячагын белгән ул. Әнием биргән вәгъдәсен үтәде. Әтием Мулланур да каршы килмәде. Анда минем 15 яшьлек туган көнемне уздырырга, каникулны шунда үткәрергә ниятләдек. Бик матур итеп Куба традицияләре буенча туган көнне уздырдык. Бик ошады миңа анда, хәтта кайтасым да килми башлады. Ахыр чиктә, әни Азнакайга үзе генә юл тотты.

Шулай итеп, София Кубада кала, укуын да шунда дәвам итә. Олимпия резервы мәктәбендә волейбол белән шөгыльләнә. Аннары исә биохимик һөнәрен үзләштерү өчен Гавана университетына укырга керә. Шул чакта кабат Татарстанны сагына башлый.

– Беләсезме, 20 яшемдә күңелемә әллә ни булды. Әтием Мулланур инде мәрхүм иде. Әнием ялгыз, аның янына кайтасым килде. Өченче курста укыганда, Казан дәүләт университетына күчендем, – дип искә ала ул. – Монда кайткач, мәчеткә барып, Суфия исемен алдым. Әнинең әбисенең исеме ул. Шулай итеп җаным тынычлык тапты. Мин ислам диненә сайладым. Әни белән мәчеткә йөри башладык. Динне өйрәнү теләге көчле булды – мәдрәсәгә укырга кердек.

София музыка белән дә шөгыльләнә. Баксаң, әтисе ягыннан бабасы заманында симфоник оркестрда эшләгән. Лино үзе дә Казанда укыганда джаз төркеменә йөргән.

– Мин дә күбрәк джаз яратам. Русча, татарча, испанча, инглизчә, итальянча, португалча җырлыйм. Музыка белән яшим. Көйләр дә язам. Башта «Авация» шоу-балетында эшләдем, аннары «Шоколат» төркемендә җырладым, – ди София. – Хәзер исә «Халыклар дуслыгы» йортында төрле чараларда катнашам. «Вертолет» яшьләр үзәгендә этно-мәдәни чаралар уздырам. Үземнең проектларым күп. Максатым – күпмилләтле Татарстан халкын берләштерү. Бездә 173 милләт вәкиле яши. Алар дус-тату. Моның нигезендә дөрес итеп алып барган сәясәт ята. Балаларга кечкенәдән үк төрле милләтләрнең мәдәниятен өйрәтеп үстерергә кирәк дип саныйм. Сабыйлар өчен дә проектлар әзерлим. Үзем Кубаны да, Татарстанны да якын итәм. Кубага барсам – андагы ризыкларны яратам. Алар дөге, фасольгә өстенлек бирә. Өстәлләрендә ногыт борчагы, яшелчәләр, тавык ите, җиләк-җимеш һәм татлы ризыклар тора. Татарлар чәй эчсә, алар тәмләп каһвә эчә. Андагы кебек каһвә башка бер җирдә дә юк. Татарстанда исә бәрәңге тәкәсе, бәлеш, гөбәдия, өчпочмак, кыстыбыйны яратып ашыйм.

София Мария-Бенита исемле кыз тәрбияли. Аны татар бакчасына биргән.

– Кызымның әтисе Павел белән Бауман урамында таныштык. Бер-беребезне аңлап яши идек. Бераздан аралар суынганын сиздек. Мин кубадагыча фикер йөртәм. Ирем дә акыллы булып чыкты. Дус-тату гына аерылыштык. Кызым исә әтисен дә, мине дә ярата. Алар Павел белән аралашып тора, – ди София. – Тагын кияүгә чыгар идем. Иремнең татар, мөселман динендә булуын телим. Мин – ирек ярата торган хатын. Иҗатыма каршы килмәгән кеше кирәк. Үз тиңемне очратсам, аны бәхетле итәр өчен бар көчемне куярмын. Иҗатка килгәндә, төрле телләрдәге җырлар янәшәсендә татарныкын да халыкка чыгарасым килә. Милләтара дуслыкны ныгытыр өчен тагын да күбрәк проектлар алып барыр идем. Дус-тату яшәү балаларыбыз өчен бик кирәк.

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Баш мөхәррир –
САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 7405 данә
Гомуми тираж – 17243 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 357

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ

420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.

www.vatantat.ru

info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru

89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР

222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-73, 222-09-67 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы
222-09-67 – фән һәм мәгариф
222-09-64 – әдәбият, сәясәт һәм дин
222-09-66 – информация, спорт, тәрҗемә, оператор
222-09-67 – хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+